**Программа эчтәлеге:**


| | |
|---|---|
| Программаның паспорты | |
| БҮЛЕК I.  Аңлатма язуы | |
| БҮЛЕК II. Якынча тематик план | |
| БҮЛЕК III. Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр | |
| БҮЛЕК I V. Программа эчтәлеге | |
| БҮЛЕК  V.  Методик ярдәмлек | |
| БҮЛЕК VI. Кулланган әдәбият | |
| БҮЛЕК VII.Якынча календарь-тематик план | |
| БҮЛЕК  VIII. Планлаштырылган эшнең нәтиҗәлеге | |
| Кушымталар | |

**Программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | “ Яран гөл”<br>5 -7 яшьлек мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен экология буенча яраклаштырылган белем һәм тәрбия бирү программасы |
| **Программаны үтәүче** | Татарстан Республикасының Теләче муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе - 2 нче номерлы балалар бакчасы<br>Телефон: 21- 4-14 |
| **Юридик адрес** | 420080, Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Теләче авылы, Молодежная урамы, 13А |
| **Төр** | Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе |
| **Программаның максаты** | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның экология өлкәсендәге белемнәрен арттыру, аларның танып – белү мөмкинлеген үстерү, күзәтүләрне анализлап, нәтиҗә ясарга өйрәтү; табигатькә сакчыл караш тәрбияләү. |
| **Программаның бурычлары** | 1. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга - үсемлекләрне танып, дөрес итеп исемнәрен атарга, дөрес тәрбияләү күнекмәләрен белергә өйрәтү.<br>2. Туган як табигатенә мәхәббәт тәрбияләү, табигать кочагында үзен дөрес тоту, җирне, суны пычратмау, яшеллекне саклау һәм тәрбияләү.<br>3. Балаларның утырткан үсемлекләргә карата игътибар иттерү, чагыштыру, кызыксынучанлыкларын үстерү. |
| **Программаны тормышка ашыру вакыты** | 1 ел |
| **Программа кем өчен исәпләнгән** | 5 -7 яшьлек мәктәпкәчә яшьтәге балалар |

| | |
|---|---|
| • **Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре** | **Ел ахырына балалар нәрсәләр белергә тиеш:**<br>• Балалар агач, куак, кыргый һәм культуралы үсемлекләрне танып, дөрес итеп исемнәрен атарга тиеш (һәрбер төрдән 4-5 үсемлек исеме).<br>• Үсемлекләрнең үзенчәлекләрен санап күрсәтә, тышкы билгеләре буенча таный белергә.<br>• Үсемлекләрнең төрләрен таный белергә тиеш.<br>• Балалар интерьерның нәрсә икәнен, аның төрләрен, гөлләр композициясенә нинди гөлләр сайлап алырга, композицияне төзи белергә.<br>• Урманда йөрү кагыйдәләрен белергә.<br>• Табигатьне саклау чараларын белергә.<br>• Кызыл китапка кергән үсемлекләрне, җәнлекләрне санап чыгарга. Үсемлекләрне нинди шартларда сакларга һәм үрчетә белергә.<br>• Урман – күп катлы йортның, катларын санап чыгарга, кемнәр яшәгәнен әйтә белергә.<br>**Балалар ел ахырына нинди эш күнекмәләрен белергә тиеш:**<br>• Балалар мөстәкыйль рәвештә су сибә, туфракны йомшарта, яфракларыннан тузан сөртә белергә.<br>• Гөлнең үсентесен утырта белергә<br>• Яшелчә орлыкларын утырта белергә.<br>• Яшелчә орлыкларын башкалардан аера, чыныктыру ысуллары буенча орлыкларын бүрттерә, ашлама, суында тота, салкынга куеп чыныктыра белергә.<br>• Үсемлекләрдән композиция, панно, гербарий, флористика, мозаика төзи белергә. |

**Кереш өлеш**

Җир елый, ишетәсезме? Мин ишетәм!
Челтерәп аккан чишмәләрем кая киткән?
Җир елый, ишетәсезме? Мин ишетәм!
Сандугачлы талкайларны кемнәр кискән?
Табигатьне кемнәр шулай әрәм иткән?
Кешеләрдә миһербанлык кая киткән?
Җир елый, ишетәсезме? Мин ишетәм!
Бу гүзәллек, бу җир шары яшәр микән?

Кеше – табигатьнең аерылгысыз бер өлеше. Ул табигатьтән башка бер генә көн, сәгать, минут та яши алмый. Табигать кешене ашата, эчертә, киендерә. Шуңа күрә дә табигатькә мөнәсәбәт, кешеләргә мөнәсәбәт кебек үк шәфкатьле булырга тиеш.

Балаларда табигатькә мәрхәмәтле караш кечкенәдән үк тәрбияләнсә генә, ул аларның күңелендә чын гуманлылык рәвешендә урын ала. Аларда табигатьнең матурлыгын тоя, аны яклый, саклый, кадерли белү хисләре тәрбияләү – әйләнә- тирә белән танышу бердәм аралашу эшчәнлегенең һәм башка чараларның төп максатларыннан берсе.

Безнең Теләче №2 балалар бакчасында балаларны экологик белем белән коралландыру, аларда табигатьне яклау, ярату хисләре тудыру, сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү юнәлешендә шактый эш башкарыла. Кече яшьтән бирелгән тәрбия, балаларның киләчәк тормышында, һичшиксез, уңай йогынты ясар.

Табигать бездән ярдәм көтә. Аның матурлыгы һәм байлыгы безнең кулда. Табигатьне саклау өчен без үз бурычыбызны үтәргә тиеш.

Әйдәгез бергәләп табигать сагына басыйк!

## БҮЛЕК I. Аңлатма язуы

“Яран гөл” экология буенча яраклаштырылган белем һәм тәрбия бирү программасы, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның экология өлкәсендәге белемнәрен арттыру, аларның танып – белү мөмкинлеген үстерү, күзәтүләрне анализлап, нәтиҗә ясарга өйрәтү; табигатькә сакчыл караш тәрбияләү **максатыннан** чыгып эшләнде.

**Белем бирү максаты:** Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга - үсемлекләрне танып, дөрес итеп исемнәрен атарга, дөрес тәрбияләү күнекмәләрен белергә өйрәтү.

**Бурычлар:**

1. Балаларны куаклар, агачлар, үсемлекләр: (бакча, кыр, болын үсемлекләре, яшелчәләр, бүлмә гөлләре, иген культуралары) белән таныштыру.
2. Үсемлекләр тормышындагы үзенчәлекләр (үсү, чәчәк ату, җимеш бирү һ.б.) турындагы күзаллауларын киңәйтү.
3. Тышкы билгеләре буенча аларны таный, исемнәрен әйтә белергә өйрәтү.
4. Балаларны мөстәкыйль рәвештә гөлләргә су сибү, чистарту, туфракны йомшарту, үсенте белән үрчетергә өйрәтү.
5. Табигый материалдан гербарий, панно, флористика, мозаика төзергә өйрәтү.
6. Балаларны интерьер төрләре белән таныштыру, гөлләр композицияләрен төзеп утыртырга өйрәтү.
7. Балаларга урманның кешеләр тормышында һәм табигатьтәге әһәмияте, экосистеманың урмандагы җанварларга яшәү өчен төп шарт икәнен аңлату.
8. Урманда йөрү кагыйдәләре белән танышытыру, аларны үтәргә күнектерү.
9. Балаларны табигатьне саклау кагыйдәләре белән таныштыру.
10. Кызыл китаптан үсемлекләр, җәнлекләрне табигый шартларда саклау һәм үрчетү урыннары, туган як музее турында төшенчә бирү.

**Тәрбияви максат:** Туган як табигатенә мәхәббәт тәрбияләү, табигать кочагында үзен дөрес тоту, җирне, суны пычратмау, яшеллекне саклау һәм тәрбияләү.

**Бурычлар:**

1. Балаларда табигатьнең матурлыгын күрә белергә, аңа карата кызыксыну уяту.
2. Табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.
3. Үсемлекләрне үстерергә теләк уяту.
4. Хезмәт кешеләренә хөрмәт тәрбияләү.
5. Балаларда дуслык һәм бер – береңә ярдәм итү теләге уяту.
6. Балаларда дисциплина һәм пөхтәлек тәрбияләү.

**Үсеш алу максаты:** Балаларның утырткан үсемлекләргә игътибар иттерү, чагыштыру, кызыксынучанлыкларын үстерү.

**Бурычлар:**

1. Балаларда үсемлекләргә карата игътибарлык һәм хәтердә калдыру сәләтен үстерү.
2. Балаларны тирә - юньне күзәтергә һәм хезмәт күнекмәләрен үстерү.
3. Балаларда табигатькә карата кызыксынучанлык, чагыштыра белү сәләтен үстерү.
4. Балаларда хезмәткә карата эстетик зәвык үстерү.

“Яран гөл” экология буенча яраклаштырылган белем бирү программасы Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәктәпкәчә тәрбия буенча норматив документларына, “Туганнан алып мәктәпкә кадәр” исемле тәрбия һәм белем бирү программасына (пилотный варианты) (М.:Мозаика-Синтез,2014), “Программаның милли-төбәк юнәлеше” (К., Мәгариф, 2009) һәм Федераль дәүләт белем бирү стандартларында күрсәтелгән 5 белем бирү өлкәсе (“Физик үсеш”, “Социаль-аралашу үсеше”, “Танып белү үсеше”, "Нәфис-нафәсәти үсеше", "Сөйләм үсеше" ) буенча куелган бурычларына туры китереп иҗат ителде. Әлеге программа Федераль дәүләт белем бирү стандартларының “ Танып белү” белем бирү өлкәсен тулысынча яктырта. Программа эчтәлеге Борһанова Р.А. ның. " Туган як табигате белән таныштыру" (Казан.: Мәгариф, 1997 ел) методик ярдәмлегенә нигезләнеп төзелгән. Баларга экологик тәрбия бирү эшен тиешле юнәлештә алып бару өчен , программага түбәндәге методик китаплар ярдәм итте:

- “Природа и ребенок» /Программа экологического образования дошкольников/ред: Енакай Т.М. , Мазитова Г.Ш., В.З. Шигапова В.З.) КАЗАНЬ: РИЦ “Школа”, 2002
- “Туган телдә сөйләшәбез”: 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек./ Төз.: З.М. Зарипова, Л.Н. Вәҗиева, Р.С. Зөфәрова һ.б. – Казан: ФОЛИАНТ, 2012;
- Куцакова Л.В. “Трудовое воспитание в детском саду. Для занятий с детьми 3-7 лет.- М.: МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2014 (учебно-методический комплект к программе “От рождения до школы” (в соответствии с ФГОС);
- Н.А.Рыжова “Экологическое образование в детском саду” М.: “Карапуз”, 2001
- Файзуллина С.А. “Комнатное цветоводство “ - Йошкар –Ола.: 1992 ел;
- Капронова Н.Н. “Комнатные растения в интерьере” - М.: Сфера, 1989 ел;

Методик китаплардан программага - эшчәнлек, экскурсия, күзәтү, тәҗрибә үткәрү, табигать почмагындагы хезмәт, кул хезмәте, дидактик уеннар үткәрү буенча методик алымнар кулланылды, практика өлешен үземнең тәҗрибәмннән алып төзедем.

"Яран гөл" программасы 5-7 яшьлек мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен төзелде. Тәкъдим ителә торган программа 1 ел өчен эшләнгән. Программа буенча белем бирү эшчәнлеге атнага ике тапкыр, 25-30 мин, балаларның шөгыльдән тыш буш вакытларында (режим моментларында) үткәреләчәк. Экология буенча белем бирү эшчәнлеге теория һәм практика өлешләреннән тора һәм күбрәк практика буенча эшчәнлекләр каралган.

"Яран гөл" программасы буенча эшчәнлек: әңгәмә, уен, эксперимент үткәрү, мөстәкыйль эшчәнлек , экскурсия, күзәтү , тәҗрибә үткәрү, кул хезмәте, рәсем ясау, табигать почмагында хезмәт, утырту эшләре формасында алып барыла.

Туган як табигате белән таныштырганда түбәндәге методлар һәм алымнар кулланыла:

**Күзәтү**

Педагог ярдәмендә балалар үсемлекләрне табигать почмагында һәм табигый шартларда күзәтәләр. Күп тапкыр күзәтүләр процессында бала үзләштереп кенә калмый, күренешләрнең һәм предметларның үзлекләрен, сыйфатларын, бер – берсе белән белдерә, аның күзәтүчәнлеге, фикер йөртүе, сөйләме үсә.

Балалар белән урман, парк, су буена, кырга һәм башка җиргә **экскурсияләр, прогулкалар** оештырыла.

**Төрле уеннар** белән таныштыру процессында өстәл, дидактик уеннар, шулай ук вак ташлар, балчык, ком, су һ.б. әйберләр кулланыла.

Табигатькә мәхәббәт, сак караш, кызыксыну тәрбияләү, күзаллауларын киңәйтү өчен табигать почмагында, яшелчә бакчасында, чәчәклектә, практик эшчәнлекләрдә балаларның **хезмәте** оештырыла. Балаларны көз көне яшелчә бакчасыннан яшелчәләрне җыеп алу, орлыклар җыю, түтәлләр казу, чәчәк атучы гөлләрне грунттан тере почмакка күчерү эшләренә тарту. Кыш көне карны агач, куак төпләренә өергә, кошларга җимлекләр ясап җим ашатып тору, март аенда рассада өчен яшелчә, иген культуралары, чәчәк орлыклары чәчү, бәйрәмнәр өчен чәчәк үстерү эшләре планлаштырыла. Яз көне бакчада җир казу,орлыклар (яшелчә, чәчәк) чәчү, үсентеләрне күчереп утырту, ә җәй айларында җим йомшарту, чүп утау, түтәлләргә һәм чәчәк клумбаларына су сибу эшләрендә катнашу каралган. Кул хезмәтендә төрле табигый материалдан композиция, панно, флористика, гербарий, мозаика төзү эшчәнлекләре кертелә.

**Педагогның сөйләме, әңгәмә, әдәби әсәрләр уку, рәсемнәр карау** балаларның күзаллауларын киңәйтүдә зур урын тота. Гомумән балаларны туган як табигате белән таныштыру һәм алардан тыш та планлаштырылачак һәм алып барылачак.

**Педагогның бурычы** – балаларның сорауларын канәгатьләндереп, күзаллауларын киңәйтеп, кайбер төшенчәләрен системага китерү һәм тулыландыру, табигать белән сак эш итүне тәрбияләү, күзәтүчәнлекләрен белергә омтылышларын, яратучанлыкларын үстерү һәм үзенең туган табигатенә мәхәббәт тәрбияләүдән гыйбарәт.

"Яран гөл" программасында 1 һәм 2 нче ярты еллыкка контроль тикшерү эшләре каралган. Белем дәрәҗәсе - ул программаның теория нигезләрен күрсәтә, ә күнекмә һәм осталык ул баланың практик эшчәнлегендә алган әзерлеген билгели. Педагог өчен бу, программаның үтәлеш дәрәҗәсен билгеләп, киләчәктә өйрәтү процессына өстәмәләр кертүгә ярдәм итә, ә ата-аналар өчен үз баласының хезмәт җимешен күрергә ярдәм итә. Программада контроль эшләре: КВН, викторина, бәйрәм иртәсе, тренинглар, конкурслар, күргәзмәләр формасында алып барыла .

Программада башка эшчәнлек белән беррәттән массакүләм һәм индивидуаль чаралар каралган. Массакүләм чаралар төрләренә : бәйрәм иртәләре, конкурслар, КВНнар, экскурсия, тренинглар,уеннар һ.б. керә.

**БҮЛЕК II. Якынча тематик план**

| №п/п | Бүлек исеме | Барлыгы | Эшчәнлек саны | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Теория | Практика |
| 1 | Кереш . | 2 | 1 | 1 |
| 2 | “Җирдәге яшеллек” | 10 | 4 | 6 |
| 3 | “Урман күп катлы йорт” | 10 | 5 | 5 |
| 4 | “Икмәк бар нәрсәдән олы” | 3 | 2 | 1 |
| 5 | “Нәрсә ул панно, композиция,флористика?” | 5 | 1 | 4 |
| 6 | “Табигатьне саклыйк” | 10 | 7 | 3 |
| 7 | “Табигать почмагы” | 11 | 5 | 6 |
| 8 | “Без үсемлекләр үстерәбез” | 6 | 2 | 4 |
| 9 | “Язгы бакча эшләре.” | 10 | 1 | 9 |
| 11 | Йомгаклау . | 3 | - | 3 |
| Барысы | | 70 | 28 | 42 |

**1. Бүлек: “Җирдәге яшеллек”**

Бу бүлектә балаларны кыр, болын, урман, дарулы һәм агулы үсемлекләр , бакча чәчәкләре белән таныштыру, үсемлек яшәеш рәвеше турындагы белемнәрен системалаштыру,баету максатлары куела. Бигрәк тә Кызыл китапка кергән үсемлекләр белән танышалар, аларны рәсемнән танырга өйрәнәләр. “Җирдәге яшеллек” бүлегендә: сәяхәтләр, дидактик уеннар, бакча эшләре, күзәтүләр кебек практик эшчәнлекләр каралган.

**2. Бүлек: “Урман күп катлы йорт”**

Бу бүлектә балаларны урман: анда үсүче агачлар, куаклар, үсемлекләр, урман җәнлекләре, тере һәм тере булмаган табигатьтәге үзгәрешләр, Татартсан урманнары, урманда йөрү кагыйдәләре белән таныштыру- максат итеп куела. Балаларны урман үрнәгендә экологик система булдыру, башка җан ияләре белән тыгыз бәйләнештә торуын , табигатьтә һәрбер үсемлек, хайван аерым бер урын алып торуын һәм күп катлы йорт булганын аңлату. Балаларга урманның кешеләр тормышында һәм табигатьтәге әһәмияте аңлатыла.

**3. Бүлек: “Икмәк бар нәрсәдән дә олы”**

Бу бүлектә балалар икмәкнең кайдан килгәнен, иген культураларын танырга, аларны үстерергә, аның өчен шартлар тудырырга өйрәнәләр.

**4. Бүлек: “Нәрсә ул панно, композиция, флористика?”**

Бу бүлектә балалар, төрле табигать материалларын кулланып, композиция, панно , флористика ясау кагыйдәләре белән танышалар.

**5. Бүлек: “Табигатьне саклыйк”**

Бу бүлектә балаларны экология, Кызыл китап, саклана торган үсемлекләр һәм җәнлекләр белән таныштыралар. Туган як табигатенә мәхәббәт тәрбияләүне дәвам иттерү, табигать кочагында үзеңне дөрес тоту: җир, суны пычратмау, яшеллекне һәм җан ияләрен саклау кирәклеген аңлату кебек максатлар куела. Балалар рәсем ясый, дидактик уеннарда катнашалар, экологик сукмак буенча сәяхәткә чыгалар, кошларга җимлекләр ясыйлар.

**6. Бүлек: “Табигать почмагы”.**

Бу бүлектә тәрбияче балаларны бүлмә гөлләре, аларны үрчетү буенча вегетатив ысуллары (ботактан, яфрактан, мыекчадан) белән таныштыра. Үсемлекләр һәм аларның яшәеше өчен мөһим роль уйнаган табигать шартлары арасындагы бәйләнешне аңлый, күрә белергә; үсемлекләрдәге үзгәрешләрнең сәбәпләрен аңларга, төшенергә ярдәм итү (яфраклары кипкән –су җитми; акрын үсә-туклыклы матдәләр җитешми һ.б). Табигать почмагын эстетик яктан бизәү максатыннан интерьер төрләре темасы буеча эшчәнлекләр кертелә. Анда балалар гөлләрдән композиция төзеп утыртырга өйрәнәләр. Бүлмә гөлләре белән таныштырганда үсемлекләргә үсү өчен кирәкле булган яктылык, җылылык, дымның әһәмияте аңлатыла.

**7. Бүлек: “Без үсемлекләр үстерәбез”.**

Март - апрель айларында балалар яшелчә һәм җиләк-җимешләр белән танышалар, орлыкларын аерырга өйрәнәләр.Утырту алдыннан орлыкларны әзерләү төрләре: бүртгерү, минераль ашламалар кертү, чыныктыру кебек тәҗрибәләр үткәрелә. Табигать почмагында суган, укроп, помидор, борыч, чәчәк орлыкларын утырту каралган. Көндәлек тормышта педагог балаларны чәчкән һәм утырткан үсемлекләргә игътибар иттерү өчен, тишелеп чыккан шытымнарны күзәтергә, бер-берсе белән чагыштырга өйрәтә. Бу темага карата елның төрле вакытында төрле әңгәмәләр, дидактик уеннар, рәсем ясау, күзәтү көндәлеген билгеләү, тәҗрибә, утырту эшләре, табигать почмагында хезмәт кебек дәресләр планлаштырыла.

**8. Бүлек: “Язгы бакча эшләре.”**

Бу бүлектә балалар белән язгы бакча эшләре каралган: яшелчә бакчасына язгы экскурсия, җир казу, яшелчә түтәле ясау, тамыразыклар утырту, чәчәк орлыкларын чәчәклеккә чәчү, гөл үсентеләрен чәчәклеккә күчереп утырту.

Бакча эшләре балаларда үсемлекләрне дөрес утырту, тәрбияләү күнекмәләрен булдырыга, хезмәтне сөяргә, күзәтүчәнлекне үстерергә, үсемлекләргә карата мәхәббәт тәрбияләргә өйрәтә.

**БҮЛЕК III. Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр:**

- Балалар агач, куак, кыргый һәм культуралы үсемлекләрне танып, дөрес итеп исемнәрен атарга тиеш (һәрбер төрдән 4-5 үсемлек исеме).
- Үсемлекләрнең үзенчәлекләрен санап күрсәтә, тышкы билгеләре буенча таный белергә.
- Үсемлекләрнең төрләрен аера белергә тиеш.
- Балалар интерьерның нәрсә икәнен, аның төрләрен, гөлләр композициясенә нинди гөлләр сайлап алырга, композицияне төзи белергә.
- Урманда йөрү кагыйдәләрен белергә.
- Табигатьне саклау чараларын белергә.
- Кызыл китапка кергән үсемлекләрне, җәнлекләрне санап чыгарга. Үсемлекләрне нинди шартларда сакларга һәм үрчетә белергә.
- Үсемлекләрне чагыштыра белергә.
- Урман – күп катлы йортның, катларын санап чыгарга, кемнәр яшәгәнен әйтә белергә.
- Үсемлекләрнең тәрбияләү чараларын белергә.

**Ел ахырында үзләштерелергә тиешле эш күнекмәләре:**

- Балалар мөстәкыйль рәвештә су сибә, туфракны йомшарта, яфракларыннан тузан сөртә белергә.
- Гөлнең үсентесен утырта белергә
- Яшелчә орлыкларын утырта белергә.
- Яшелчә орлыкларын башкалардан аера, чыныктыру ысуллары буенча орлыкларын бүрттерә, ашлама, суында тота, салкынга куеп чыныктыра белергә.
- Саклана торган үсемлекләрне саклый һәм үрчетә белергә.
- Мөстәкыйль рәвештә табигать почмагындагы үсемлекләрне тәрбияләргә.
- Кипкән үсемлекләрдән, орлыклардан композиция, панно, гербарий, флористика, мозаика төзи белергә.
- Мөстәкыйль рәвештә табигатьтә күзәтү үткәрә белергә.
- Күзәтү көндәлеген ясый белү.
- Үсентене күчереп утырта белергә.
- Җир казый белү;
- Яшелчә түтәле ясый белү;
- Орлыклардан тамыразыклар утырта белү;
- Чәчәк орлыкларын чәчәклеккә чәчә белү;
- Гөл үсентеләрен чәчәклеккә күчереп утырта белү;

## БҮЛЕК IV.  Программа эчтәлеге

**1. Кереш   (2эшчәнлек)**

**Теория өлеше (1эшч.)**

“Үсемлекләр дөньясы” әңгәмә. Түгәрәкнең максаты һәм бурычлары.

**Практика өлеше (1эшч. )**

Эш кораллары белән танышу. Куркынычсызлык буенча инструктаж.

**2. “Җирдәге  яшеллек” (10 эшчәнлек )**

**Теория өлеше ( 4 эшч.)**

Бакча чәчәкләре.

Урман үсемлекләре.

Дару үләннәре.

Агулы үсемлекләр.

**Практика өлеше (6 эшч.)**

Чәчәклеккә сәяхәт. Бакча чәчәкләрен күзәтү, орлыкларын җыю.

Орлыкларны киптерү ысулы белән таныштыру. Кагәзь конвертлар ясап орлыкларны әзерләп кую.

Бакча чәчәкләрен чүлмәккә күчереп үтырту.

Болынга сәяхәт. Болын үсемлекләре белән танышу,  кыргый үсемлекләрне  җыеп киптерү.

Дидактик уен “Кайсый ярый, кайсы ярамый”, “Мин кайда үсәм”.

Уен-викторина “Чәчәкләр - тормыш яме”

**3. “Урман күп катлы йорт” (10 эшчәнлек.)**

**Теория өлеше (5 эшч.)**

Агачлар һәм куаклар. Дидактик уен “Кайсы агачтан яфрак?”.

“Агачлар ни диләр” шигырен уку, эчтәлеген сөйләү.

Тере һәм тере булмаган әйберләр турында сөйләшү.

Татартсан урманнары. Урманны кемнәр саклый.

Урманда йөрү кагыйдәләре.

**Практика өлеше (5 эшч.)**

Агачлар паркына эксурсия. Көзге яфраклар, табигый материаллар җыю, киптерү, җыеп кую.

Көзге яфраклардан аппликация ябыштыру.

Урманда нәрсәләр үсә һәм яши. Дидактик уен “Урман күп катлы йорт”.

Табигый материалдан уенчыклар ясау.

“Сөмбелә бәйрәме”ндә катнашу (“Көзге могҗиза” күргәзмәсе)

**4. “Икмәк бар нәрсәдән дә олы” (3 эшчәнлек.)**

**Теория өлеше (2 эшч.)**

Әнгәмә “Икмәк кайдан килә” Дидактик уен “Иң элек нәрсә булган”.

Иген культуралары белән танышу, альбом карау.

**Практика өлеше (1 эшч.)**

Иген бөртекләреннән аппликация төзү.

**5. “Нәрсә ул композиция, панно, флористика” (5 эшчәнлек)**

**Теория өлеше (1 эшч.)**

Әңгәмә “Нәрсә ул композиция, панно, флористика”

**Практика өлеше (4 эшч.)**

“Җәйге фантазия” кипкән үләннәрдән панно төзү, эзлекле эш кагыйдәләре белән таныштыру.

“Гаҗәеп букет” композициясен ясау.

“Яңа ел” композициясен ясау.

**I ярты еллыкка контроль эш.**

**6. “Табигатьне саклыйк” (10 эшчәнлек)**

**Теория өлеше (7 эшч.)**

Нәрсә ул экология? Кызыл китап белән танышу.

Саклана торган үсемлекләр һәм хайваннар. Дидактик уен “Нәрсә әйбәт, нәрсә начар?”

Тере табигать янәшәсендә тере булмаган табигатьнең роле. Дидактик уен “Кем һәм нәрсә”

Һава, су, җылылык һәм яктылык.

Тереклек ияләренә сакчыл караш. Үсемлекләргә сакчыл караш.

Җир астында кемнәр яши.

“Туган якны, туган җирны ярату – экологик сукмак буенча сәяхәт”.

**Практика өлеше ( 3 эшч.)**

Агач паркына кышкы экскурсия.

Кошларга җимлек ясау, аларны ашату.

Экологик КВН.

**7. “Табигать почмагы” (11 эшчәнлек)**

**Теория өлеше (5 эшч.)**

Әңгәмә “Без гөлләр үстерәбез”. “Гөлләр” уен-пазл.

Бүлмә гөлләре белән танышу. Дидактик уен “Үзенчәлеге буенча уйлап тап”.

“Үсемлекләрне корткычлардан саклау”-әңгәмә. Гөлләрне санитар яктан тикшерү. “Интерьер нәрсә ул?” - әңгәмә. Гөлләр төрләре белән таныштыру. (Субтропик гөлләр, папоротник гөлләре, чүл гөлләре)

Интерьер төрләре белән танышу. Гөлләр композициясен төзү кагыйдәләре.

**Практика өлеше (6 эшч.)**

Гөлләр рәсеме ясау.

Бүлмә гөлләренең тәрбия төрләре. Табигать почмагында хезмәт.

Вегетатив утырту ысуллары. Яран гөлнең үсентесен утырту. Күзәтү көндәлеген ясап кую.

Папоротник гөлләрдән “Бакча” композициясен төзү.

Чүл гөлләре белән композиция.

Уен-тренинг “Гөлләр”

**8. “Без үсемлекләр үстерәбез” (6 эшчәнлек)**

**Теория өлеше (2 эшч.)**

Әңгәмә “Яшелчә бакчасына сәяхәт”. Табышмаклар әйтү. Сюжетлы- рольле уен “Яшелчәләр, җиләк-җимеш кибете”.

Яшелчә орлыклары белән таныштыру. Дидактик уен “Кайсы орлыктан нинди яшелчә үсә?”.

**Практика өлеше ( 4 эшч.)**

Яшелчә орлыклары . Утырту алдыннан орлыкларны әзерләү төрләре: чыныктыру, минераль матдәләр кертү, бүрттерү.

Орлыкларны утырту кагыйдәләре. Помидор орлыкларын утырту.

Суган, петрушка, укроп орлыкларын утырту. Күзәтү көндәлеген ясау. Дидактик уен “Иң элек нәрсә булган?”

Уен-тренинг “Яшелчә, җиләк-җимеш”

**9. “Язгы бакча эшләре” (10 эшчәнлек)**

**Теория өлеше (1 эшч.)**

Әңгәмә: “Язгы бакча эшләре”

**Практика өлеше ( 9 эшч.)**

Агач паркына, яшелчә бакчасына язгы экскурсия.

Җир казуның эш тәртибе белән таныштыру

Яшелчә түтәле ясау. Тамыразыкларны утырту өчен түтәлне әзерләү (тырмалау, чүпләрен җыю, сызыклар сызу).

Яшелчә орлыкларын утырту.

Чәчәк орлыкларын чәчәклеккә чәчү

Яран гөл  үсентеләрен чәчәклеккә күчереп утырту

Яшелчә үсентеләрен (помидор, борыч, кыяр) бакчага күчереп утырту

Әңгәмә: "Җәйге бакча эшләре"

**II ярты еллыкка контроль эш.**

**10. Йомгаклау. (3 эшч әнлек.)**

**Практика өлеше (3 эшч.)**

"Табигать-тиңсез хәзинә" бәйрәменә әзерлек эшләре.

Экологик бәйрәм "Табигать-тиңсез хәзинә"

Йомгаклау дәресе. Табигать кочагына экскурсия. Ярыш уеннары.

БҮЛЕК V. Методик ярдәмлек

**Өйрәтү - тәрбия эшләре**

| № п/п | Чишеләсе бурычлар | Бурычларны чишү юллары | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | **Балалар коллективын оештыру буенча эшчәнлек** | - Уен-викторина “Чәчәкләр - тормыш яме”<br>-“Көзге могҗиза” конкурсы (яшелчә, җиләк-җимеш, табигый материаллардан кул эшләре)<br>- “Сөмбелә бәйрәме”<br><br>- Күргәзмә “Яңа ел табигате”<br>- Уен-тренинг “Табигать күренешләре”<br>-Экологик КВН.<br><br><br>- Уен-тренинг “Гөлләр”<br><br>конкурс<br>- «Тәрәз төбендә нәни бакча » күргәзмәсе<br>- уен-тренинг “Яшелчә, җиләк-җимеш;<br>- Экологик бәйрәм “Табигать-тиңсез хәзинә;<br>- Экологик бәйрәм “Табигать-тиңсез хәзинә; | Октябрь<br>Октябрь<br><br>Октябрь-Ноябрь<br><br>Декабрь<br>Каникул<br>Февраль<br><br><br>Март<br><br><br>Апрель<br>Апрель<br>Май<br>Май |
| 2. | Ата-аналар белән эш | -ата-аналар җыелышы, программаның максатлары һәм эшләре белән таныштыру, эшчәнлек өчен кирәкле эш кораллары һәм инвертарьлар булдыру;<br>-Экология конкурсларында, күргәзмәләрдә катнаштыру<br>-ата-аналар белән ел дәвамында индивидуаль консультац ияләр, әңгәмәләр үткәрү;<br>-әти-әниләрне ачык шөгыльләр, конкурс, викториналарга чакыру. | Сентябрь<br><br><br><br>ел дәвамында<br><br>ел дәвамында<br><br>ел дәвамында |
| 3. | Күмәк чараларда | - “ Сөмбелә” ; | Октябрь |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | катнашу. | - “Яңа ел» ;<br>- “Карга боткасы” ;<br>- Балалар бакчасында үткәрелә торган экологик атналыкларда катнашу;<br>- Бөтенроссия, республика, район күләмендә экологик акция , операцияләрдә катнашу;<br>- Интернет буенча бөтенроссия, республика, район, балалар бакчасында үткәрелә торган экологик конкурсларда, күргәзмәләрдә катнашу, публикацияләр җибәрү.<br>- көзге һәм язгы өмәләрдә катнашу | Декабрь<br>Апрель<br>ел дәвамында<br>ел дәвамында<br>ел дәвамында<br>ел дәвамында |

**Программа өчен тудырылган мөмкинлекләр.**

1. **“Туган телдә сөйләшәбез” Укыту-методик комплектындагы күрсәтмәлелелек һәм балалар өчен тарату материаллары .**
2. **Күрсәтмә альбомнары:**
   - “Бакча чәчәкләре”
   - “Кыргый үсемлекләр”
   - “Дару үләннәре”
   - “Агулы үсемлекләр”
   - “Природа Татарстана”
   - “Бүлмә гөлләре”
   - “Яшелчәләр”
   - “Табигатьне саклагыз”
3. **Дидактик уеннар:**
   - “Гаҗәеп чәчәкләр”
   - “Исемен әйт”
   - “Мин кайда үсәм”
   - “Кайсы ярый, кайсы ярамый”
   - Урман – ул кошлар, хайваннар, үсемлекләр йорты”
   - “Кайсы агачтан яфрак”
   - “Иң элек нәрсә булган”

- Үзенчәлеге буенча уйлап тап” һ.б.

4. **Гербарийлар:**
   - “Агач һәм куак яфраклары”
   - “Иген культуралары”
   - “Кыргый үсемлекләр”
5. **Уен – мозаика:**
   - “Иген культуралары”
   - “Гөлләр”
   - “Яшелчәләр”
6. **Рәсемнәр**
7. **Экология буенча әдәби китаплар:** К.В.Закирова. “Балачак аланы”: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия. – Казан: РИЦ, 2011
8. **Учебно-развивающая литература по окружающему миру:**
   - Шустова И. Б. «Азбука. Звери и птицы России» - М.: ДРОФА, 2007
   - Шустова И. Б. Азбука. Растения России - М.: ДРОФА, 2007
   - Тамбиев А.Х. «Кто в лесной норе живет?» - М.: ДРОФА, 2007
   - Тамбиев А.Х. «Кто в кустарнике живет?» - М.: ДРОФА, 2007
   - Гарибова Л.Б. «Царство грибов» - М.: ДРОФА, 2007
   - «Животные русского леса»: потешки, сказки, загадки. Стихи и рассказы. - М.: ДРОФА, 2007
   - «Большая книга о природе» (стихи, рассказы, загадки, пословицы) - М.: ДРОФА, 2006
9. **Табигый материаллар әзерләү:** кипкән агач яфраклары, үләннәр, чәчәкләр, башаклар, күркәләр, агач орлыклары, мүк, агач ботаклары, агач гөмбәсе, пенопласт, конфет коробкалары, төсле кәгазьләр һ.б.
10. **Кибет туфрагы, көл, ком, керамзит әзерләү.**
11. **Утырту эшләре өчен кирәкле җиһазлар һәм инвентарь булдыру.**

- утырту эшләре өчен балаларга клеенкалы алъяпмалар;
- җиңсәләр
- өстәл клеенкалары
- рассада өчен агач һәм пластмасс ящиклар
- рассада үстерү өчен төпле һәм тыпсез чүлмәкләр, кассеталар.
- гөл чүлмәкләре
- 2 таз

- пластмасс уенчык көрәкләр һәм тырмалар
- агач таякчыклар
- су савытлары
- лейкалар
- пульвизаторлар
- балалар өчен кыска саплы щеткалар
- мусор өчен совок
- материал кисәкләре, салфеткалар
- полиэтилен пакетлар, майонез  савытлары һ.б.

**12. Утырту өчен яшелчә, чәчәк орлыклары  булдыру.**

## БҮЛЕК VI: Кулланылган әдәбият:


1. Федеральный закон от 29.12.2012 года №273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации»;
2. Приказ Минобрнауки России от 17.10.2013 № 1155 «Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования»;
3. Закон РТ №16 от 03.03.2012 г. “О государственных языках РТ и других языках в РТ”,
4. Закон «Об образовании» РТ от 19 октября 1993 года № 1982 с дальнейшими изменениями;
5. Постановление Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 15.05.2013 № 26 «Об утверждении СанПин 2.4.1.3049-13 «Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации режима работы дошкольных образовательных организаций»;
6. Федеральные государственные образовательные стандарты основной общеобразовательной программы дошкольного образования и условий ее реализации;
7. "ОТ РОЖДЕНИЯ ДО ШКОЛЫ" Тәрбия һәм белем бирү программасы (пилотный вариант) / Ред: Веракса Н.Е., Комарова Т.С., Васильева М.А. . – М.: МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2014. ( с ФГОС таләпләренә туры килә)
8. Шаехова Р.К. “Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы” – Казан.: РИЦ, 2012
9. “Природа и ребенок» /Программа экологического образования дошкольников/ ред: Енакай Т.М. , Мазитова Г.Ш., В.З. Шигапова В.З., КАЗАНЬ.: РИЦ “Школа”, 2002
10. Борһанова Р.А. “Туган як табигате белән таныштыру” , Казан.: Мәгариф, 1997 ел.
11. “Туган телдә сөйләшәбез”: 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек./ Төз.: З.М. Зарипова, Л.Н. Вәҗиева, Р.С. Зөфәрова һ.б. – Казан: ФОЛИАНТ, 2012;
12. Балачак аланы; балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия/ Төз.: Закирова К.В..- Казан: РИЦ, 2011
13. Кашапова М.Ф. "Иң гүзәл тел-туган тел": балалар бакчалары өчен сөйләм үстерү буенча методик кулланма.- Казан: РИЦ "Школа", 2009
14. Кашапова М.Ф. "Уйныйк әле балалар"- Казан: РИЦ "Школа", 2011

15. Куцакова Л.В. “Трудовое воспитание в детском саду. Для занятий с детьми 3-7 лет.- М.: МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2014 (учебно-методический комплект к программе “От рождения до школы” (в соответствии с ФГОС);
16. Рыжова Н.А. “Экологическое образование в детском саду” М.: “Карапуз”, 2001 ел.
17. Файзуллина С.Я. “Комнатное цветоводство “ - Йошкар –Ола.: 1992 ел
18. Капронова Н.Н. “Комнатные растения в интерьере”, Мәскәү, 1989 ел.
19. Шаехова Р.К. , Закирова К. В. “Иҗат баскычлары” , Казан, 2001 ел.
20. Дыбина О.В., Рахманова Н.П., Щетинина В.В. Неизведанное рядом: Занимательные опыты и эксперименты для дошкольников /О.В. Дыбина (отв. Ред.), - М.: ТЦ Сфера, 2005. – 192 с.
21. Павленко Л.Ф. В гармонии с природой. Часть 1. Старшая группа: программа и методическое пособие для воспитателей дошкольных учреждений. – Ульяновск: ИПК ПРО, 1999. – 100 с.
22. Проблемы воспитания экологической культуры детей дошкольного возраста. // Экологизация сознания. – 1995. - №2
23. Базарнов В.Ф. Экскурсия как форма экологического образования. – Томск, 2004
24. Барковская О.М. Содержание, цель и задачи программы начального экологического воспитания. // Начальная школа. – 2004. - №2. – с. 32-33.
25. Виноградова Н.Ф., Куликова Т.А. Дети, взрослые и мир вокруг. – М.: Просвещение, 1993. – 128с.
26. Градобоева Т. Экологическое воспитание детей. // Дошкольное воспитание. – 1988. - №7. с. 6-8.
27. Дерим-Оглу Е.Н., Фролова Н.А. Материалы для проведения экскурсии в смешанный лес. // Начальная школа. – 2003. - №4. – с. 20-23.
28. Золотова Е.И. Знакомим дошкольников с миром животных. – М.: Изд., Просвещение;
29. Запартович Б.Б., Криворучко Э.Н., Соловьева Л.М., С любовью к природе. – М.: Педагогика, 1983. – 232 с.
30. Как знакомить дошкольников с природой / Под ред. П.Г. Саморуковой. – М.: Просвещение, 1978. – 223 с.
31. Калегина Н.Г. Опыт работы по экологическому воспитанию дошкольников. – Казань, 1994. – 139 с.
32. Королева А. Естествознание для малышей. Программа экологического воспитания детей старшей группы. – 1988. – 10. с. 48-54.

33. Кирикэ Г. Ребенок и природа. // Дошкольное воспитание. – 1993. - №7. с. 3-9.
34. Мельчаков Л.Ф. Воспитание и развитие детей в процессе обучения природоведению. – М.: Изд. Просвещение, 2001. – 185 с.
35. Николаева С.Н. Методика экологического воспитания дошкольников: Учебное пособие для студентов средних и высших педагогических учебных заведений. – М.: Издат. центр «Академия», 1999. – 184 с.
36. Никитина Э. Природа как средство воспитания. // Дошкольное воспитание. – 193. №7 – с. 6-12.
37. Николаева С.Н. Методическое пособие к программе «Зеленая тропинка»: Пособие для воспитателей по подготовке детей к школе. – М.: Просвещение, 2001, 63с.
38. Обзор зарубежных и отечественных программ экологического образования и воспитания детей. // Дошкольное воспитание. – 2002. - №7. с. 52-64.
39. Павленко Л.Ф. В гармонии с природой. Часть 1. Старшая группа: программа и методическое пособие для воспитателей дошкольных учреждений. – Ульяновск: ИПК ПРО, 1999. – 100 с.
40. Проблемы воспитания экологической культуры детей дошкольного возраста. // Экологизация сознания. – 1995. - №2.
41. Плешаков А.А. Изучение темы «Сохраним природу России» в новом курсе природоведения IV класс четырехлетней начальной школы. // Начальная школа. – 2004. - №5. – с. 24-30.
42. Педагогические модели организации экологического образования в ДОУ. // Дошкольное воспитание. – 2000. -№9. с.40-46.
43. Рыжова Н. О проекте «Стратегии экологического образования: итоги и перспективы первого этапа всероссийского эксперимента». // Дошкольное воспитание. – 2001. - №6. с. 18-20.
44. Рыжова Н.А. Воздух-невидимка. Пособие по экологическому образованию дошкольников. М.: ЛИНКА – ПРЕСС, 1998. – 128 с.
45. Типикина В. Радость общения с природой. // Дошкольное воспитание. – 1993. - №7. с.22-24.
46. Унучек Л. Роль экологических знаний в воспитании бережного отношения к природе. // Дошкольное воспитание. – 1983. - №7. с. 4-6.
47. Узбеков И. О проблемах экологического воспитания в детских дошкольных учреждениях. // Начальная школа. – 2005. - №2. – с. 44-45.
48. Фокина В. Экологическое воспитание – это воспитание нравственности, духовности и интеллекта. // Дошкольное воспитание. – 1995. - №7. с. 11-14.

49. Формирование у дошкольников осознанного отношения к природным явлениям и объектам. // Опыт педагогов Оренбуржья. Оренбург, 1999.
50. Харитонова Л. Исследовательская деятельность дошкольника. // Дошкольное воспитание. – 2001. - №7. с. 32-34.
51. Цветкова И.В. Экологическое образование, игры и проспекты. - Москва, 1996.
52. Чаус Б.Ю., Чаус З.А. Экологические сказки. // Начальная школа. – 2012. - №11. – с. 44-47.
53. Шиленок Т. Помощь педагогу в работе по экологическому воспитанию дошкольников. // Дошкольное воспитание. – 1992. - №7-8. с. 5-7.
54. Экологическое воспитание дошкольников: пособие для специалистов дошкольного воспитания (Автор-составитель С.Н. Николаева). – М.: ООО «Фирма «Издат-во АСТ», 1998. – 320 с.
55. Экологическое воспитание дошкольников: практическое пособие / под. ред. Л.Н. Прохоровой. – 2-е изд., испр., и доп. – М.: АРКТИ, 2014. – 72 с.

**БҮЛЕК VII. Якынча календарь-тематик план**

| № п/п | Темалар | Үткәрү вакыты | Эшчәнлек саны | Шөгыль төре |
|---|---|---|---|---|
| 1. | **1. Кереш дәресе (2 эшчәнлек)** “Үсемлекләр дөньясы” әңгәмә. Түгәрәкнең максаты һәм бурычлары. | Сентябрь | 1 | теория |
| 2. | Эш кораллары белән танышу. Куркынычсызлык буенча инструктаж | Сентябрь | 1 | практика |
| | **2. “Җирдәге яшеллек” (10 эшчәнлек)** | | | |
| 3. | Бакча чәчәкләре. | Сентябрь | 1 | теория |
| 4. | Чәчәклеккә сәяхәт. Бакча чәчәкләрен күзәтү, орлыкларын җыю. | Сентябрь | 1 | практика |
| 5. | Орлыкларны киптерү ысулы белән таныштыру. Кагәзь конвертлар ясап орлыкларны әзерләп кую. | Сентябрь | 1 | практика |
| 6. | Бакча чәчәкләрен чүлмәккә күчереп утырту | Сентябрь | 1 | практика |
| 7. | Болынга сәяхәт. Болын үсемлекләре белән танышу, кыргый үсемлекләрне җыеп киптерү. | Сентябрь | 1 | практика |
| 8. | Урман үсемлекләре | Сентябрь | 1 | теория |
| 9. | Дару үләннәре. | Октябрь | 1 | теория |
| 10. | Агулы үсемлекләр | Октябрь | 1 | теория |
| 11. | Дидактик уен “Мин кайда үсәм” | Октябрь | 1 | практика |
| 12. | Уен-викторина “Чәчәкләр - тормыш яме” | Октябрь | 1 | практика |
| | **3.“Урман күп катлы йорт” (10 эшчәнлек)** | | | |
| 13. | Агачлар һәм куаклар. Дидактик уен “Кайсы агачтан яфрак?”. | Октябрь | 1 | теория |
| 14. | Агачлар паркына эксурсия. Көзге яфраклар, табигый материаллар җыю. Киптерү, җыеп кую. | Октябрь | 1 | практика |
| 15. | “Агачлар ни диләр” шигырен уку, эчтәлеген сөйләү | Октябрь | 1 | теория |
| 16. | Көзге яфраклардан аппликация ябыштыру. | Октябрь | 1 | практика |
| 17. | Тере һәм тере булмаган әйберләр турында сөйләшү. | Ноябрь | 1 | теория |
| 18. | Татарстан урманнары. Урманны кемнәр саклый. | Ноябрь | 1 | теория |
| 19. | Урманда нәрсәләр үсә һәм яши. Дидактик уен | Ноябрь | 1 | практика |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | “Урман күп катлы йорт”. | | | |
| 20. | Урманда йөрү кагыйдәләре. | Ноябрь | 1 | теория |
| 21. | Табигый материалдан уенчыклар ясау. | Ноябрь | 1 | практика |
| 22. | “Сөмбелә бәйрәме”ндә катнашу (“Көзге могҗиза” күргәзмәсе) | Ноябрь | 1 | практика |
| | **4. “Икмәк бар нәрсәдән дә олы” (3 эшч.)** | | | |
| 23. | Әңгәмә “Икмәк кайдан килә”. Дидактик уен “Иң элек нәрсә булган” | Ноябрь | 1 | теория |
| 24. | Иген культуралары белән танышу, альбом карау. | Ноябрь | 1 | теория |
| 25. | Иген бөртекләреннән аппликация төзү. | Декабрь | 1 | практика |
| | **5. Нәрсә ул композиция, панно, флористика (5 эшчәнлек)** | | | |
| 26. | Әңгәмә “Нәрсә ул композиция, панно, флористика” | Декабрь | 1 | теория |
| 27. | “Җәйге фантазия” кипкән үләннәрдән панно төзү эзлекле эш кагыйдәләре белән таныштыру. | Декабрь | 1 | практика |
| 28. | “Гаҗәеп букет” композициясен ясау. | Декабрь | 1 | практика |
| 29. | “Яңа ел” композициясен ясау. | Декабрь | 1 | практика |
| 30. | I ярты еллыкка контроль эш. | Декабрь | 1 | практика |
| | **6. Табигатьне саклыйк ( 10 эшчәнлек)** | | | |
| 31. | Нәрсә ул экология? Кызыл китап белән танышу | Декабрь | 1 | теория |
| 32. | Саклана торган үсемлекләр һәм хайваннар. Дидактик уен “Нәрсә әйбәт, нәрсә начар?” | Декабрь | 1 | теория |
| 33. | Тере табигать янәшәсендә тере булмаган табигатьнең роле. Дидактик уен “Кем һәм нәрсә” | Январь | 1 | теория |
| 34. | Һава, су, җылылык һәм яктылык | Январь | 1 | теория |
| 35. | Тереклек ияләренә сакчыл караш. Үсемлекләргә сакчыл караш. | Январь | 1 | теория |
| 36. | Агач паркына кышкы экскурсия. | Январь | 1 | практика |
| 37. | Җир астында кемнәр яши. | Январь | 1 | теория |
| 38. | “Туган якны, туган җирны ярату – экологик сукмак буенча сәяхәт”. | Январь | 1 | теория |
| 39. | Кошларга җимлек ясау, аларны ашату. | Февраль | 1 | практика |
| 40. | Экологик КВН. | Февраль | 1 | практика |
| | **7. Табигать почмагы (11 эшчәнлек)** | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 41. | Әңгәмә “Без гөлләр үстерәбез”. “Гөлләр” уен-пазл | Февраль | 1 | теория |
| 42. | Бүлмә гөлләре белән танышу. Дидактик уен “Үзенчәлеге буенча уйлап тап”. | Февраль | 1 | теория |
| 43. | Гөлләр рәсеме ясау. | Февраль | 1 | практика |
| 44. | “Үсемлекләрне корткычлардан саклау” -әңгәмә Гөлләрне санитар яктан тикшерү. | Февраль | 1 | теория |
| 45. | Бүлмә гөлләренең тәрбия төрләре. Табигать почмагында хезмәт. | Февраль | 1 | практика |
| 46. | Вегетатив утырту ысуллары. Яран гөл үсентесен утырту. Күзәтү көндәлеген ясап кую | Февраль | 1 | практика |
| 47. | Интерьер нәрсә ул ? - әңгәмә. Гөлләр төрләре белән таныштыру.( Субтропик гөлләр, папоротник гөлләре, чүл гөлләре) | Март | 1 | теория |
| 48. | Интерьер төрләре белән танышу. Гөлләр композициясен төзү кагыйдәләре. | Март | 1 | теория |
| 49. | Папоротник гөлләрдән “Бакча” композициясен төзү. | Март | 1 | практика |
| 50. | Чүл гөлләре белән композиция | Март | 1 | практика |
| 51. | Уен-тренинг “Гөлләр”. | Март | 1 | практика |
| | **8. Без үсемлекләр үстерәбез (6 эшчәнлек)** | | | |
| 52. | Әңгәмә “Яшелчә бакчасына сәяхәт”. Табышмаклар әйтү. Сюжетлы- рольле уен “Яшелчәләр, җиләк-җимеш кибете”. | Март | 1 | теория |
| 53. | Яшелчә орлыклары белән танышу.<br>Дидактик уен “Кайсы орлыктан нинди яшелчә үсә?”. | Март | 1 | теория |
| 54. | Яшелчә орлыклары. Утырту алдыннан орлыкларны әзерләү төрләре: чыныктыру, минераль матдәләр кертү, бүрттерү. | Март | 1 | практика |
| 55. | Орлыкларны утырту кагыйдәләре.<br>Помидор орлыкларын утырту. | Апрель | 1 | практика |
| 56. | Суган, петрушка, укроп орлыкларын утырту. Күзәтү көндәлеген ясау. Дидактик уен “Иң элек нәрсә булган?” | Апрель | 1 | практика |
| 57. | Уен-тренинг “Яшелчә, җиләк-җимеш” | Апрель | 1 | практика |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **9. Язгы бакча эшләре.(10 эшчәнлек)** | | | |
| 58. | Әңгәмә: “Язгы бакча эшләре” | Апрель | 1 | теория |
| 59. | Агач паркына, яшелчә бакчасына язгы экскурсия. | Апрель | 1 | практика |
| 60. | Җир казуның эш тәртибе белән таныштыру | Апрель | 1 | практика |
| 61. | Яшелчә түтәле ясау. Тамыразыкларны утырту өчен түтәлне әзерләү (тырмалау, чүпләрен җыю, сызыклар сызу). | Апрель | 1 | практика |
| 62. | Яшелчә орлыкларын утырту. | Апрель | 1 | практика |
| 63. | Чәчәк орлыкларын чәчәклеккә чәчү | Май | 1 | практика |
| 64. | Яран гөл үсентеләрен чәчәклеккә күчереп утырту | Май | 1 | практика |
| 65. | Яшелчә үсентеләрен (помидор, борыч, кыяр) бакчага күчереп утырту | Май | 1 | практика |
| 66. | Әңгәмә: “Җәйге бакча эшләре” | Май | 1 | практика |
| 67. | II ярты еллыкка контроль эш. | Май | 1 | практика |
| | **10. Йомгаклау. (3 эшчәнлек)** | | | |
| 68. | “Табигать-тиңсез хәзинә” бәйрәменә әзерлек эшләре. | Май | 1 | практика |
| 69 | Экологик бәйрәм “Табигать-тиңсез хәзинә” | Май | 1 | практика |
| 70 | Йомгаклау дәресе. Табигать кочагына экскурсия. Ярыш уеннары. | Май | 1 | практика |

**БҮЛЕК VIII. Планлаштырылган эшнең нәтиҗәлеге.**

| №п/п | Бүлек исеме ( тематик план буенча) | Белем һәм күнекмәләр | Тикшерү механизмы |
|---|---|---|---|
| **1** | **Кереш .** | -Куркынычсызлык кагыйдәләрен әйтә белү;<br>-Эш кораллары белән дөрес куллана белү; | -Дидактик уеннар. Практик эш. |
| **2** | **“Җирдәге яшеллек”** | -Балалар бакча чәчәкләре кыр, болын, урман үсемлекләрен танып, дөрес итеп исемнәрен әйтә белү (һәрбер төрдән 4-5 үсемлек исеме).<br>-Агулы һәм дару үләннәрен аера белү, исемнәрен әйтә белү. Дару үләнәренең файдасы турында сөйләү;<br>-Үсемлекләрнең үзенчәлекләрен санап күрсәтә, тышкы билгеләре буенча таный белү;.<br>-Үсемлекләрнең төрләрен аера белү;<br>-чәчәкнең үсентесен утырта белү; | -Уен-викторина “Чәчәкләр - тормыш яме” |
| **3** | **“Урман күп катлы йорт”** | -Балалар агач, куакларны танып, дөрес итеп исемнәрен өйтә белү; (һәрбер төрдән 4-5 үсемлек исеме)<br>- Агач һәм куакны орлыгы, яфрагы буенча аера белү;<br>- Тере һәм тере булмаган предметларны аера, тирә-як мохите һәм тере организм тормышы арасындагы бәйләнешен аңлата белү;<br>- Урман – күп катлы йортның, катларын санап чыгарга, кемнәр яшәгәнен әйтә белү; | -“Сөмбелә бәйрәме”ндә катнашу (“Көзге могҗиза” күргәзмәсе) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | - Урманда йөрү кагыйдәләрен әйтә белү;<br>-Табигатьне саклау чараларын әйтә белү;<br>- Мөстәкыйль рәвештә табигатьтә күзәтү үткәрә белү;<br>- Табигый материалдан уенчыклар ясый белү; | |
| **4** | **“Икмәк бар нәрсәдән олы”** | -Иген культураларын аера, исемнәрен әйтә белү;<br>- Игенченең мактаулы хезмәте, икмәкнең нинди юллар аша табынга килүе турында сөйли белү;<br>- Иген бөртекләреннән бизәкләр ясый белү; | - Дид.уеннар.<br>-Күргәзмә. |
| **5** | **“Нәрсә ул панно, композиция, флористика?”** | -Кипкән үсемлекләрдән, орлыклардан - композиция, панно, гербарий, флористика, мозаика төзи белү;. | “Яңа ел” күргәзмәсе |
| **6** | **“Табигатьне саклыйк”** | -Табигатьне саклау чараларын әйтә белү;.<br>-Кызыл китапка кергән үсемлекләрне, җәнлекләрне санап чыга белү;.<br>-Үсемлекләрне нинди шартларда сакларга һәм үрчетә белү;.<br>- Урманда йөрү кагыйдәләрен белү;. | Экологик КВН. |
| **7** | **“Табигать почмагы”** | -Бүлмә гөлләрен тышкы билгеләре буенча таный, аларның исемнәрен әйтә, үзенчәлеге буенча аера белү;<br>- Балалар интерьерның нәрсә икәнен, аның төрләрен, гөлләр композициясенә нинди гөлләр | Уен-тренинг “Гөлләр”. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | сайлап алырга, композицияне төзи белү;.<br>- Балалар мөстәкыйль рәвештә су сибә, туфракны йомшарта, гөлнең яфракларыннан тузан сөртә белү;.<br>- Гөлнең үсентесен утырта белү; | |
| **8** | **“Без үсемлекләр үстерәбез”** | - Тышкы билгеләре буенча яшелчә, җиләк-җимешләрне танып, исемнәрен әйтү;<br>-Яшелчә орлыкларын аеру, утырта белү;<br>- Яшелчә орлыкларын чыныктыру ысуллары буенча орлыкларын бүрттерә, ашлама, суында тота, салкынга куеп чыныктыра белү;<br>- Күзәтү көндәлеген тутыра белү; | -Уен-тренинг “Яшелчә, җиләк-җимеш”<br>-«Тәрәз төбендә нәни бакча » күргәзмәсе |
| **9** | **“Язгы бакча эшләре.”** | -җир казый белү;<br>- яшелчә түтәле ясый белү;<br>- орлыклардан тамыр-азыклар утырта белү;<br>- чәчәк орлыкларын чәчәклеккә чәчә белү;<br>- гөл үсентеләрен чәчәклеккә күчереп утырта белү; | Язгы бакча эшләрендә күренә. |
| **10** | **Йомгаклау .** | -Ел буена тупланган белем һәм күнекмәләрне күрсәтә белү; | Экологик бәйрәм “Табигать-тиңсез хәзинә” |

## “Яран гөл” программасының экологик тәрбия буенча эш нәтиҗәсе күрсәткечләре:

| **№ пп** | **Баланың исем, фамилиясе** | Агач, куак, кыргый һәм культуралы үсемлекләр не рәсемнән танып күрсәтә белү, исемнәрен санап чыгу (һәрбер төрдән 4-5 үсемлек исеме); | Үсемлекләрнең тышкы билгеләре буенча үзенчәлекләрен санап чыгу, күрсәтә белү; | Гөлләргә мөстәкыйль рәвештә су сибә, туфрагын йомшарта, гөлнең яфракларыннан тузан сөртә белү | Гөлнең үсентесен утырта белү; | Урманда йөрү кагыйдәләрен санап чыгу | Кызыл китапка кергән үсемлекләрне, җәнлекләрне санап чыга белү;.(4-5 исем) | Табигатьне саклау чараларын әйтә белү | Яшелчә-җиләк җимешләрнең исемнәрен әйтә, орлыкларын аера белү. | Яшелчә орлыкларының чыныктыру ысулларын санап чыгу. | Яшелчәләрне мөстәкыйль рәвештә орлыктан һәм үсентедән утырта белү | Җир казый, яшелчә түтәле ясый белү; | Кипкән үсемлекләрдән, орлыклардан - композиция, панно, гербарий, флористика, мозаика төзи белү | **Барлыгы:** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |

**Ю – югары,**

**У – уртача,**

**Т – түбән**

**Кушымта №1**

МБМББУ-Теләче №2 балалар бакчасының
1квалификацион категорияле тәрбиячесе
Мөхәммәдиева Миләүшә Фәнис кызы

**Эшчәнлек темасы: “Бүлмә гөлләре белән танышу”**

**5-6 яшьлек балалар өчен**

**Максат:** Балаларның бүлмә гөлләре турында булган белемнәрен киңәйтү, гөлләрне ничек тәрбияләү төшенчәләренә өйрәтү, гөлләргә сакчыл караш тәрбияләү.

**Тәрбия бурычы:** Бүлмә гөлләренә карата соклану хисләрен һәм мәхәббәт уяту, аларны карап үстерү теләген тәрбияләү;

**Үстерү бурычы:** Эшчәнлек аша, балаларның кызыксынучанлык, хәтер, игътибарлылык, логик фикерләү сәләтен үстерү.

**Белем бирү бурычы:** Бүлмә гөлләре белән таныштыруны дәвам итү, аларны тәрбияләү буенча шартлы тамгалар белән таныштыру, үзләренә генә хас үзенчәлекләре буенча танып, бер-берсеннән аерырга , аларны дөрес тәрбияләү кагыйдәләренә өйрәтү, кеше тормышында аларның әһәмиятен аңлату.

**Төп белем бирү өлкәсе:** танып белү үсеше (табигать дөньясында ориентлашу)

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше (сөйләм үстерү), танып белү үсеше (танып белү-тикшеренү эшчәнлеге), социаль-комуникатив үсеш (табигать почмагында хезмәт), физик үсеш (физик культура)

**Методик алымнар һәм чаралар**: сюрприз момент, техник чаралар куллану, проблемалы сорау, ситуация кую, таныштыру, ныгыту, аңлату, физкультминут, танып белү-тикшеренү эшчәнлеге (сенсор үсеш), нәтиҗә ясау, күрсәтү, балалар хезмәте, балалар белән шөгыльдә өйрәнгәннәрне ныгыту, йомгаклау.

**Җиһазлау:**

- Аудиоязма: “Гөлкәйләрем” җыры (М.Разов сүзләре, В. Агапов көе);
-Магнитофон;
-“Бүлмә гөлләре” темасына презентация;
-Интерактив такта, проектор;
- Бүлмә гөлләре (яран гөл, алоэ, фикус);
- Бүлмә гөлләренең шартлы тамгалары.
- Бүлмә гөлләрен тәрбияләү буенча:
  - ✓ эш кораллары ( кечкенә таякчыклар, көрәкләр, тырмалар) – 2 набор
  - ✓ лейкалар- 2 шт.
  - ✓ Пульверизатор- 1 шт
  - ✓ Йомшак тукымалар- 2 шт

- ✓ Пумалалар-2 шт
- ✓ Клеенкалы фартуклар

**Сүзлек өстендә эш:** алоэ, пульверизатор.

**Алдан үткәрелгән эш:** бүлмәдә үскән гөлләрне күзәтү

**Эшчәнлек төзелеше:**

1. **Кереш:** Сюрприз момент "Чәчәкләр патшабикәсе керә". Үзе белән таныштыра, бүлмә гөлләре белән сөйләшә.
2. **Төп өлеш:**

❖ **"Бүлмә гөлләре" темасына презентация карау:**

-Проблемалы сорау: Бүлмә гөлләре безгә кайдан килгән?

- Бүлмә гөлләренең шартлы билгеләре белән таныштыру

- Бүлмә гөлләре. Алоэ гөле белән танышу. Гөлләргә тамгалар кую.

❖ **Танып белү-тикшеренү эшчәнлеге:** Сенсор үсеш. Бүлмә гөлләрен борын, күз, кул- бармаклар белән тою, биремнәр үтәү. Нәтиҗә ясау.

❖ **Физминутка "Гөлләр"**

❖ **Практик эш:** Табигать почмагында хезмәт:

- Гөлләргә су сибу кагыйдәләре. Практик эш.
- Гөлләрнең төпләрен йомшарту буенча кагыйдәләр. Практик эш.
- Гөлләрнең тузаннарын сөртү буенча киңәшләр. Практик эш.

3. **Йомгаклау:** Балалар белән шөгыльдә өйрәнгәннәрне ныгыту.

**Эшчәнлек барышы:**

**1.Кереш. Сюрприз момент :** "Гөлкәйләрем" җырына (М.Разов сүзләре, В. Агапов көе) бии-бии "Чәчәкләр патшабикәсе керә.

**Чәчәкләр патшабикәсе:** Исәнмесез балалар! Сез мине таныйсызмы? Мин "Чәчәкләр патшабикәсе" булам. Минем чәчәкләрем урманда, болында, кырда, чәчәклектә хәттә сезнең тәрәз төпләрендә гөлләр булып үсә. Ел буена мин аларны тәрбияләп, кайгыртып яшим: кояш белән иркәлим, назлыйм, җылы яңгырларым белән сыйлыйм, йомшак җилләрем белән сафландырам . Шуңа күрә дә алар, яз, җәй, иртә көз айларында матур итеп чәчәк атып утыралар. Ә сез балалар минем гөлләрем - гөлкәйләремне карыйсызмы, дөрес тәрбиялисезме? (балалар җавабы)

-Ә беләсезме балалар, гөлләр белән сөйләшергә кирәк , аларның телен аңласаң, аларны тәрбияләү бик җиңел. Телисезме без гөлләр белән сөйләшеп алабыз. (Чәчәкләр патшабикәсе балалар белән бүлмә гөлләре почмагына киләләр).

**Чәчәкләр патшабикәсе:** Исәнмесез минем гөлләрем-гөлкәйләрем! Ничек хәлләрегез? Авырмыйсызмы? Сезне карыйлармы, тәрбиялиләрме? (Ч.п. тыңлап торган була). Яранкаем әле кайчан кечкенә идең, хәзер зур матур гөлгә әйләнгәнсең. Ә сиңа миләшкәем күрәм, күләгәдә рәхәт, чәчәк атып утырасың. (гөлләрне сыпыра)

-Дусларым! Гөлләр сүзләре буенча, сез тәрбияче апагыз белән аларны яхшы тәрбиялисез икән. Тик сез гөлләр турында барысын да белеп бетермисез икән . Телисезме мин сезне бүлмә гөлләре белән тирәнрәк таныштырам. Әйдәгез урыннарыгызга утырыгыз, игътибар белән мине тыңлыгыз! (балалар проектор каршына барып утыралар)

1. **Төп өлеш:**

- **"Бүлмә гөлләре" темасына презентация карау**

**2 нче слайд: Проблемалы сорау:**

**Ч.П.** - Балалар уйлап карагыз әле, безнең тәрәзә төбендә чүлмәктә үсүче бүлмә гөлләре каян барлыкка килде икән? (Балалар җаваплары тыңлана)

**Ч.П.**– Балалар бүлмә гөлләре безгә җир шарының төрле почмакларыннан, җылы якларыннан килгән. Безнең гөлләр анда зур үсемлек, куак, хәтта агач булып үсә ала. Ни өчен? Чөнки анда ел буе җәй : кояш, җылы яңгырлар, уңдырышлы туфрак. Мондый шартларда кечкенә гөлдән зур агач үстереп була. Ә бездә салкын ел фассыллары бар . Шуның өчен дә кешеләр бу гөлләрне өйдә җылыда тәрәзә төпләрендә үстерәләр. Әгәр дә гөлләрне урамга алып чыгып утыртсак гөлләр көннәр салкынайгач үләрләр иде.

**3 нче слайд: Бүлмә гөлләренең шартлы билгеләре белән таныштыру.**

**Ч.П. – Ә** сез беләсезме гөлләрне тәрбияләү буенча шартлы тамгалар бар. Хәзер мин сезне бу тамгалар белән таныштырам.



Бу нинди тамга ?(кояш). Бу тамга гөлгең кояшны яратканын күрсәтә, аны кояшлы якты урынга куярга кирәклеген аңлата.



Бу нинди тамга? (кояш кара сызык белән аркылыга сызылган) Бу тамга гөлнең кояш нурларын яратмаганын күрсәтә, чөнки ул аның яфракларын пешерергә мөмкин. Шуның өчен гөлне күләгәле урынга куярга кирәк.



Бу нинди тамга? (су тамчысы) Бу тамга гөлнең су яратканын, аның туфрагы гел дымлы булуын сорый.  Димәк бу гөлгә  ешрак су сибергә кирәк. Суны сирәк сибү



Бу тамгада  су тамчысы кара сызык белән аркылы сызылган. Димәк гөл артык суны яратмый, коры җырне ярата. Аңа сирәк су сибәргә кирәк.

**4 нче слайд: Бүлмә гөлләре.**

**Ч.П. -** Ә хәзер гөлләрне искә төшерик.

-Бу  нинди гөл кем белә? (яран гөл). Әйе,  пеларгония, халык  аны яратып яран гөл  дип йөртә.  Яран гөл бик файдалы, аның яфраклары белән бик күп авыртуларны дәвалап була. Балалар “Яран гөл” янында нинди тамга күрәсез?(балалар җавабы)  Дөрес. Яран гөл кояшлы урынны ярата,  тик күп су сибүне яратмый, артык дымлы туфрак тамырларын зарарлый.

- Гүзәл “Яран гөл”гә тиешле тамганы табып, урнаштырып куй.

**5  нче слайд: Ч.П. -** Бу  нинди гөл кем белә? (Фикус). Фикус  озын булып үсә торган торган үсемлек.  Аның яфраклары зур, шома, нык.  Балалар “Фикус” гөле янында нинди тамга күрәсез? (балалар җавабы)  Дөрес. Фикус яктылыкны ярата,  артык дымны яратмый, суны сипкәндә җир кибеп өлгерергә тиеш,шуның өчен аны атнага 2 тапкыр гына сибәләр. (1 бала фикуска тиешле тамга табып  куя)

**6 нчы слайд: Алоэ гөле белән танышу.**

**Ч.П.**    - Ә бу гөлне мин үзем таныштырам. Бу гөл “Алоэ” дип атала. Кабатлагыз! (кабатлыйлар) Алоэ да безгә җылы Африка якларыннан килгән, ул анда бик зур агач булып үсә. Халык  аны “Меңъяшәр”  дип исемләгән, чөнки ул балалар бик күп еллар үсә ала икән.  Алоэ  гөленең сабагы турыга үсә, яфраклары очлаеп ян – якка киткән. Калын инәле яфраклары эчендә лайлалы сыекча бар, аның белән дәвалананалар. Ә сезнең балалар, салкын тигәндә,  тогылган борынарагызны дәваларга була.  Чүлдә үскәнгә күрә, алоэ кояшны ярата.  Алоэ гөлен кояш караган тәрәз төпләренә куярга кирәк,  күп су сибүне яратмый .  Димәк нинди тамга куябыз? (1 бала тамганы табып гөл төбенә урнаштыра)

- **Танып белү-тикшеренү эшчәнлеге:  Сенсор үсеш.  Бүлмә гөлләрен борын, күз, кул- бармаклар белән тою, биремнәр үтәү.**

**Ч.П** : Ә хәзер урыннарыбыздан торып гөлләр белән тикшеренүләр алып барабыз.

1. Балалар кайсы гөлнең яфрагы йомшак,  хуш исле?  Һәрбер гөлнең яфрагын сак кына сыпырып карагыз һәм иснәгез?  Күрсәтегез нинди гөл?  (Яран гөл) Дөрес балалар.
2. Кайсы гөлнең яфрагы  йомшак, калын,  сусыл һәм энәле? (алоэ)
3. Кайсы гөлнең яфрагы  зур, каты, нык резина кебек. (фикус)

**Нәтиҗә ясау:** Яран гөлнең яфрагы  хуш исле,  йомшак.  Фикус гөленең яфрагы зур каты, нык.  Алоэ яфрагы калын, йомшак, сусыл, энәле.

❖ **Физминутка “Гөлләр”**

Гөл сабагы күренде, (балалар чүгәлиләр, кул учлары белән “бөре” ясыйлар)
Һәм кояшка үрелде. (кулларын өскә күтәреп, аяк очларына басып  әкрен генә  өскә үреләләр )
Тибрәлде талгын җилдә, (кулларын өскә күтәреп, ян-якка тирбәләләр)
Сокланды гүзәл җиргә. (иелеп, кулларын ян -якка җәяләр)

❖ **Практик эш: Табигать  почмагында хезмәт:**

**7 слайд:  Ч.П**.: - Балалар, искә төшерик әле, гөлләр  яхшы үссен  без аларны ничек тәрбиялибез?  (су сибәбез, төпләрен йомшартабыз, тузанын сөртәбез)

❖ **Гөлләргә су сибу кагыйдәләре. Практик эш.**

**Ч.П.:** Әйе, дөрес.  Су сибу буенча мин сезгә берничә киңәш бирәм:

✓ Гөлләр өчен суны  алдан әзерләргә кирәк.

✓ Гөләргә  җылымса суны лейка  белән сибәләр.

✓ Кыш көне кешеләр карны эретеп,  җылытып сибәләр.  Җәй көне яңгыр суын сипсәң файдалырак булыр. Кар һәм яңгыр суында гөлләр өчен бик күп файдалы матдәләр бар.

✓ Гөлләргә су сипкәндә, лейка борынын гөл савытына тияр-тимәс тотарга кирәк. (Чәчәкләр патшабикәсе үзе күрсәтә)

**Ч.П.:**  Иделия, Солтан  килегез әле, бергәләп гөлгә су сибеп карыйбыз.
(Иделия, Солтан  гөлгә су сибә).

❖ **Гөлләрнең төпләрен йомшарту буенча кагыйдәләр. Практик эш.**

**8  слайд:  Ч.П.  : Гөлләрнең төпләрен йомшарту өчен берничә кагыйдә үтәргә кирәк:**

✓ Гөлләрнең төпләрен су сипкән көнне йомшартырга ярамый.

✓ Гөлләрнең төпләрен тирән итеп йомшартырга ярамый, тамырлары зарарлана.

- ✓ Гөлләрнең төпләрен чүлмәкнең кырыеннан сак кына йомшарталар

(Чәчәкләр патшабикәсе үзе күрсәтә, аннан 2 бала эшләп күрсәтә)

- ❖ **Гөлләрнең тузаннарын сөртү буенча киңәшләр. Практик эш.**

**9 нчы слайд: -Ч.П**: Гөлләр безнең чисталыкны ярата. Аларның яфракларына тузан җыела. Тузан сөртү өчен йомшак тукыма, су сиптерә торган җайланма - пульверизатор, пумала кирәк.

**10 нчы слайд: -Ч.П**: Зур , каты яфраклы гөлләрнең яфракларын йомшак тукыма белән сөртәләр. Тукыманы юешләп яфракның ике ягында сак кына сыпыралар. (фикус гөленең яфрагын сөртә) . Күрдегезме, балалар, гөлнең яфрагы чистарды. Әйдә, хәзер Әмир сөртеп күрсәтсен әле. (Әмир яфракның тузанын сөртә).

**11 нчы слайд**: **- Ч.П. -** Кайбер гөлләрнең яфраклары бәрхет сыман мамыклы, йомшак була. Аларның тузаннарын кисточка белән алалар, бу коры ысул дип атала. (Мәсәлән яран гөл, төнге миләүшә гөле) (Башта Чәчәкләр патшабикәсе пумала белән сөртеп күрсәтә, аннан 2 бала күрсәтә)

**12 нче слайд**: **Проблемалы ситуация**:

**- Ч.П.** – Балалар безнең әле **к**ечкенә, шома яфраклы гөлләр дә бар, аларны ң тузаннарын ничек сөртәбез?(балалар җавабы)

- Кечкенә, шома яфраклы гөлләрне -су сиптерә торган җайланма- пульверизатор белән сиптерергә кирәк. (2 бала күрсәтә)

**Йомгаклау:**

**Ч.П.:** - Менә балалар, мин бүлмә гөлләре турында белемнәрем белән уртаклаштым, күрсәттем. Гөлләр телен хәзер сез дә аңлыйсыздыр дип уйлыйм. Сезгә минем белән очрашу ошадымы?

**-** Балалар, сез бүген нинди гөл белән таныштыгыз ?

- Гөлләрнең нинди тамгалары була?

– Су сибү буенча нинди яңа кагыйдәләр үзләштердегез?

-Төплерен йомшарту буенча яңа кагыйдәләр?

- Нинди гөлләрне чүпрәк белән сөртәләр?

- Нинди гөлләрне пумала белән сөртәләр?

- Нинди гөлләрне пульверизатор белән сиптерәләр?

– Ә гөлләрне тәрбияләү буенча нинди яңа кагыйдәләр үзләштердегез? Су сибү буенча, төплерен йомшарту буенча, тузан сөртү буенча (балалар җавабы)

**Ч.П.:** - Әфәрин, балалар! Чәчәкләр патшабикәсе биргән белемнәрне сез бик тиз истә калдыргансыз, киләчәктә дә онытмагыз. Сез бик акыллы, хезмәт сөючән балалар

икәнсез. Мин сезнең янга буш кул белән килмәдем, очрашуыбыз истәлегенә табигать турында наклейкалар бүләк итәм. Алган белемнәрегезне кулланып, тәрбияче апагыз белән гөлләрне дөрес итеп тәрбияләгез, ә гөлләр сезгә, рәхмәт йөзеннән тәрәз төпләрендә гел шаулап чәчәк атып торырлар. Өйгә кайткач та, иренмәгез, әти-әниләрегез белән гөлләрне бергә тәрбияләгез, алган белемнәрегез белән уртаклашыгыз. Миңа китәргә вакыт балалар, ләкин мин әле сезгә тагын киләм, әле минем сезгә чәчәкләр турында бик күп............... сөйлисе бар. Саубылыгыз, киләсе очрашуларга кадәр!

**Кушымта №2**

МБМББУ-Teләче №2 балалар бакчасының
1квалификацион категорияле тәрбиячесе
Мөхәммәдиева Миләүшә Фәнис кызы

**Эшчәнлек темасы: “Икмәк кайдан килә”**

**(Зурлар төркеме)**

**Максат :**

Балаларны борынгы татар халкының иген игү культурасы белән таныштыру, аларның фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерү .

Иң кадерле ризыгыбыз икмәккә сак караш , кадер –хөрмәт , игенче хезмәтен олылау ,аның хөрмәтенә соклану хисләре тәрбияләү.

**Җихазлау:**

Бүлмәдә “ Икмәк кайдан килә “ стенд ясалган , “Элек һәм хәзер” дигән альбом , вазага арыш , бодай башаклары куелган. Кечкенә өстәлгә ашъяулык җәелгән һәм түгәрәк икмәк куелган . Бүлмәнең алгы өлешендәге өстәлдә бер тәлинкә , кашык һәм бер телем икмәк куелган .Балаларның күкрәкләренә киеп кую өчен рәсемнәр куелган .Бүлмәнең бер почмагында өстәлдә урак куелган.

**Сүзлек өстендә эш :** Урак , көлтә , сука , көлтә сугу , тәпәч .

**Дәрес барышы :**

Тәрбияче:

- Балалар игътибар белән тыңлагыз әле , мин сезгә бер ***табышмак*** әйтәм

Шушы табышмакның җавабы бүгенге дәреснең темасы булыр .

- Үзе түгәрәк , урыны түрдәрәк
- Эче тулы күзәнәк , әчкелтем , төчкелтем ,
- Я , кем әйтә , бу нәрсә ?

(Икмәк)

- Әйе , дөрес балалар бу икмәк! Икмәк –ул кешегә яшәү өчен кирәк булган иң туклыклы , иң кирәкле ризык. Без икмәкне кадерләп төрлечә атыйбыз. Ипи , ипекәй , күмәч , калач һ.б.

  Балалар менә шушы кадерле ризыгыбызның валчыгын да ташлау , таптау , әрәм итү – зур гөнаһ . Менә шушы кадерле ризыгыбыз нинди юллар үтеп табыныбызга килә икән .

  **“Ипи кайдан килә” дигән стенд карау.**

1. Кыш көне трактор басуда кар тота , ул дым күп булсын өчен кирәк .
2. Трактор җирне сукалый .

3. Трактор ашлама сибә , ул уңыш яхшы булсын өчен эшләнә .
4. Трактор җирне йомшарта .
5. Трактор җиргә орлыклар чәчә.
6. Орлыклар тишелеп чыга , самолет агу сибә , үсентеләрне корткычлардан саклый .
7. Комбайн игенне ура , суга һәм йөк машиналарына төяп элеваторга җибәрә .
8. Элеваторда игенне чистарталар һәм тегермәнгә җибәрәләр .
9. Тегермәндә он ясыйлар һәм ул оннан икмәк пешерү өчен пекарняга илтәләр .
10. Пекарняда икмәк пешерәләр һәм кибетләргә җибәрәләр .
11. Без кибетләрдән икмәкне сатып алабыз һәм ул безнең өстәлебезгә килә .

- Менә балалар икмәкне үстерү өчен никадәр эш эшләргә кирәк икәнен сез беләсез инде , шулай бит . Ә менә элек заманнарда тракторлар да , комбайннар да булмаган . Безнең борынгы бабаларыбыз ничек итеп иген иккәннәр икәнен беләсегез киләме ?

**Рәсемнәр карау “Элек һәм хәзер”**

1. Балалар җирне трактор сукалый , ә элек җирне ат белән сука тагып сукалаганнар .
2. Хезер чәчүне трактор белән чәчкеч тагып чәчәләр , ә элек кешеләр кул белән сибеп йөргәннәр.
3. Хәзер иген өлгергәч игенне комбайн ура да , суга да . Ә элек кешеләр урак белән урганнар (урак күрсәтә) һәм бәйләп көлтә ясаганнар . Шул көлтәләрне тәпәч белән сукканнар , икенче төрле әйтсәк , бөртеген аерып алганнар . Шул бөртекләрне кул белән чистартып , киптереп , җил тегермәне белән он ясаганнар һәм икмәкне үзләре өйдә пешергәннәр .

- Менә балалар безнең борынгы татар халкы шундый авырлыклар белән иген иккән . Шуңа да икмәкне кадерләү кирәк тә инде.
- Балалар хәзер азрак хәрәкәтләнеп уен уйнап алыйк әле.

**Хәрәкәтле уен “Күрсәт әле”**

***Максат :*** Балаларның алган белемнәрен ныгыту .

***Уен кагыйдәсе :*** Балалар кулга – кул тотынып түгәрәк ясап басалар .

Тәрбияче бер балага санамыш белән уенчыны сайларга куша , сайланган бала түгәрәк уртасына чыгарга тиеш . Балалар бердәм рәвештә җырлыйлар һәм уенчыга бер хәрәкәт күрсәтүен сорыйлар .Уртадагы бала шул хәрәкәтне күрсәтә .Уен барышында балалар сорауны да , җавапны да бергә җырлыйлар .

- Күрсәт әле (бала исеме) ничек чәчү чәчкәннәр ?

- Менә шулай , менә шулай , шулай чәчү чәчкәннәр .
- Күрсәт әле .... ничек урак урганнар?
- Менә шулай , менә шулай , шулай урак урганнар .
- Күрсәт әле .... ничек көлтә сукканнар ?
- Менә шулай , менә шулай , шулай көлтә сукканнар .
- Күрсәт әле .... ничек камыр басканнар ?
- Менә шулай , менә шулай , шулай камыр басканнар .

Шулай уен дәвам итә.

- *Балалар хәзер "Бала белән ипекәй" сөйләшкәнне тыңлап үтик.*

**"Бала белән ипекәй" шигыре .**

*Бала:*

- Яхшы беләм игеннең
- Кара җирдә үскәнен
- Урган чакта этинең
- Манма җиргә төшкәнен
- Нигә алтын төсле соң
- Ындырдагы кешеләр ?

*Ипекәй:*

- Үстергәнгә кадерләп
- Алтын куллы кешеләр .

*Бала:*

- Оны ап-ак ! Бу аклык
- Кайдан килгән соң аңа ?

*Ипекәй :*

- Ак булган ул , игенче
- Күңеле ак булганга .

*Бала:*

- Ашаганда телемне , йота яздым әле мин .

*Ипекәй :*

- Беләсеңме әниең , пешергәнгә тәмле мин .

*Бала:*

- Валчыгын да калдырмыйм , ашаганда табында .

*Ипекәй :*

- Әгәр эшләп ашасаң , тәмлерәк мин тагын да .

*Бала:*

- Кайдан алып безгә син , шулкадәр көч бирәсең .

*Ипекәй :*

- Миңа күпме кешенең , көче кергән беләмсең ?

Тәрбияче :

- Менә балалар икмәкнең валчыгын да , әрәм итмәскә , кадерләп кенә ашарга кирәклеген бервакытта да исегездән чыгармагыз . Бер көн кибеткә ипи кайтмаса без ипине сагынабыз шулай бит. Без ашны да , яшелчәләрне ипи белән ашыйбыз. Хәттә чәйне камырдан пешергән ризыклар белән эчәбез .
- Ә хәзер “Кыз белән икмәк” әкияте буенча инцинировка карап алыйк .

**“Кыз белән икмәк” әкияте .**

Тәрбияче :

- Балалар безнең тырыш игенчеләребез халыкны хуш исле тәмле икмәк белән тәэмин итү өчен нинди эшләр эшлиләр икән .

(Магнитофоннан әкрен генә көй яңгырый)

Әни :

(кызы Гөлназны ашарга чакыра)

- Кызым , кил әле , өстәл янына утыр әле , менә шушы ашны ипи белән аша әле . Тәмле итеп ашасаң , зур үсәрсең , матур кыз булырсың .

Гөлназ :

- Мин сезнең бу ипиегезне ашамыйм , үзегез ашагыз , миңа конфет бирегез !

Тәрбияче :

- Шул вакыт тәрәз каршына трактор килеп туктый .

Трактор :

- Мин басуны сөрдем ,тырмаладым , орлык чәчтем . Ашлык куе биек булып үсте .Башаклар алтын-сары төскә керде , “Ипи кирәкми” – дигән өчен мин Гөлназга бик ачулы !

Тәрбияче :

-Трактор янына комбайн да килеп туктый .

Комбайн :

- Күрсәтегез әле миңа ул ипи яратмаган кызны ! Мин юкка гына ашлыкны урдым-суктыммы ? Юкка гына ял итмичә эшләдемме ?

Тәрбияче :

- Комбайн янына йөк машинасы килеп туктый .

Йөк машинасы :

- Мин дә ул кыз турында ишеттем һәм бик үпкәләдем . Без шофер белән ару-талуны белмичә ашлыкны амбарга ташыдык . Бер дә юкка тырышканбыз икән.

Тәрбияче :

- Канатларын әйләндереп тегермән килеп җитә .

Тегермән :

- Монда ничек ачуланмаска . Мин бердә юкка ашлыктан он ясадыммы ? Ә Гөлназ ипигә карамыйда .

Тәрбияче :

- Тегермән артыннан мич тә калмый .

Мич:

-Мин дә аз эшләмәдем . Гөлназ өчен күпереп торган ипи пешердем .

Әни :

- Күрдеңме кызым , синең өчен күпме кеше эшләгән , тырышкан . Ә син

ипи яратмыйм дисең . Миңа синең өчен оят . Инде нишлибез ?

Гөлназ :

- Әни мин барын да аңладым . Башка киреләнмәм һәм ашны һәрчак ипи белән ашармын . Мине зинһар гафу итегез ! Сезгә барысы өчен дә зур рәхмәт ! Ипи чыннан да бик тәмле икән !

Әни :

- Рәхмәт кызым ! Инде барысын да аңладың кебек .

Тәрбияче :

- Балалар сезнең дә Гөлназ хәлендә калганыгыз юкмы ? Мин ипи ашамыйм , конфет ашыйм диеп ? (балалар җавабы)
- Ә хәзер игътибар белән тыңлагыз һәм ипи турындагы мәкальләрне истән чыгармагыз .

**Мәкальләр :**

1. Ипи - иң зур байлык .
2. Икмәк - табында нур , ул кешегә көч бирә .
3. Икмәкнең валчыгыда бездән олы , коеп ашама .
4. Икмәк хезмәт , икмәк ул тырышлык
   Икмәк яшәү , икмәк ул тереклек .
5. Икмәк җыр ул , икмәк ул гүзәллек
   Икмәк акыл һәм сихәтлек .
6. Икмәк белән кеше , кеше була ,
   Икмәк белән кеше көчле була .

Ул булмаса җирдә орыш була ,

Икмәк белән генә тормыш була .

***Анализ :***

- Балалар без бүген сезнең белән нәрсә турында сөйләштек ?
- Элек заманда җирне нәрсә белән сукалаганнар ?
- Ничек итеп орлыкларны чәчкәннәр ?
- Нәрсә белән иген урганнар ?
- Икмәкне ничек итеп кадерләп була ?

**Дәрес тәмам**

**Кушымта №3**

МБМББУ-Теләче №2 балалар бакчасының
1квалификацион категорияле тәрбиячесе
Мөхәммәдиева Миләүшә Фәнис кызы

**Тема: Помидор үсентеләрен күчереп утырту.**

(Мәктәпкә әзерлек төркеме өчен)

**Максат:** Балаларда яшелчә турындагы белемнәрен һәм тормышта кулланышын ныгыту. Яшелчәләрне кузаллап, аларның сыйфатларын сөйләргә өйрәтү. Помидор үсентесен күчереп утырту, балаларны хезмәт тәрбиясенә өйрәтү.

**Сүзлек өстендә эш:** үсенте, тыгызлау.

**Җихазлау:**

**Тәрбияче өчен:** яшелчә муляжлары, яшелчә рәсемнәре, помидор үсентеләре белән ящик, лейка, таякчык, клеенка, салфетка.

**Балалар өчен:** туфрак белән сок савытлары, таякчык, салфетка, клеенка, фартук, лейка белән су.

**Дәрес барышы:**

***Дәресне оештыру:*** Балалар ярым түгәрәк булып утыралар. Тәрбияче өстәл артында бабалар белән әңгәмә алып бара. Өстәлдә поднос белән яшелчә муляжлары куелган.

**Тәрбияче:** Балалар, бүгенге дәрестә без сезнең белән яшелчәләр турында сөйләшербез һәм помидор үсентесен утыртырга өйрәнербез.

- Әйтегез әле, минем өстәлдә подноста нәрсәләр бар ? Аларны бергә ничек дип атыйлар? ( Яшелчәләр)
- Дөрес, балалар! Ә узган елны безнең балалар бакчасында нинди яшелчәләр үсте, хәтерлисезме, санап китегез? ( балалар санап китте)
- Сез аларны ничек карап үстердегез? (без аларга су сиптек, чүпләрен утадык, җирләрне йомшартык )
- Уңыш нинди булды? (балалар җавабы)
- Балалар,хәзер елның кайсы вакыты? (яз вакыты)
- Балалар, без бүген сезнең белән помидор үсентеләрен пикировать итәргә һәм үзебезнең савытларбызга күчереп утыртырга өйрәнербез.
- Балалар, әйтегез әле помидор үсентесе нинди өлешләрдән тора? (помидор үсентесен карыйлар) (Тамыры, сабагы, яфраклары)
- Дөрес, балалар. Менә үсентеләрне савытларга күчереп утырткач, аларга көн саен су сибеп, җирләрен йомшартып, үсентенең үсешен күзәтербез.

- Ә хәзер, мин сезгә, ничек үсентене дөрес утыртырга өйрәтермен. Иң беренче үсентегә “Пикировка” ясарга кирәк . Нәрсә соң ул пикировка? –Үсентенең тамыр очындагы  җепләрне чемеп алу  була инде ул. Ә ни өчен кирәк соң ул, балалар? Үсентенең тамырларны нык булсын, яхшы үсеп китсен өчен кирәк.
- Хәзер мин сезгә үсентене дөрес күчереп утырту турында сөйләрмен һәм күрсәтермен. Кечкенә таякчык белән савыттагы җиргә чокыр ясыйм һәм саклык белән генә шул чокырга су сибәм. Җиргә су сеңгәч, сул кулыма үсентене яфракларыннан гына тотып  алам да, аны чокырга утыртам. Үсентенең тамырларын җайлап  чокырга урнаштырам. Сул кулым белән үсентене җиңел генә тотып, уң кулым белән чокырны җир белән томалыйм. Соңыннан ике кулның 2 бармагы белән үсенте төбендәге җирне тыгызлыйм һәм чокырлап калдырам. Чокырлап калдырган җирдә су җыелып кала һәм әкренләп үсентенең тамырларына сеңә.( Тәрбияче бер баланы чакыра һәм утыртып күрсәтә)
- Балалар,барыгыз да, үзегезнең өстәлләрегезгә карагыз. Һәрберегезнең өстәлендә клеенка җәелгән,  су савытларыгызда балчык тутырылган, таякчык һәм помидор үсентесе бар. Әйдәгез, хәзер помидор үсентесен үзегез утыртып карагыз! (Эш брышында тәрбияче балаларның эшләрен күзәтә һәм булыша)

**Дәресне йомгаклау:**

- Балалар без нәрсә утырттык? (помидор үсентесен утырттык)
- Үсенте яхшы үссен өчен нишләргә кирәк?(үсентегә су сибәргә, җирне йомшартырга, күзәтергә кирәк)
- Балалар бүгенге дәрес шуның белән тәмам. Барыгызда дәрестә кызыксынып, тыңлап утырдыгыз, җавапларга дөрес әйттегез, бергә эшләдегез. Афәрин балалар!
- Ә хәзер барыбызда кулларны юарга барабыз, дежурныйлар өстәлне җыештыра.

**Кушымта № 4**

**Тема: “Үсемлекләр”**

**6-7 яшьлек балалар өчен уен-биремнәр**

**Максат:**

- Балаларның үсемлекләргә карата кызыксыну уяту, сакчыл караш тәрбияләү;
- Акыл эшчәнлеген үстерү (анализлау,синтез, чагыштыру, гомумиләштерү, классификацияләү, охшату);
- Иҗади мөмкинлекләрен үстерү;
- Үсемлекләр турында белемнәрен ныгыту;

**Булсаң зирәк-әйт тизрәк**

1. Яңа ел агачы.
2. Кипкән виноград.
3. Җәрәхәткә яба торган яфрак.
4. Буратино нәрсәдән эшләнгән?
5. Сабаклары- энәле, җимешләре файдалы.
6. Нинди үсемлек безне чага?
7. Агачның җир астындагы өлеше.
8. Ачылмаган чәчәк.

**Биремнәр**

- **Бер сүз белән әйт.**

  Кыяр, кәбестә, помидор, бәрәңге;

  Лимон, банан , груша, әфлисун;

  Юкә, каен, имән, өрәңге;

  Роза, лалә, гладиолус, лилия;

  Тузганак, кыңгырау, ромашка, күкчәчәк;

  Яран, алоэ, фикус, кактус;

  Арыш, бодай, арпа, карабодай;

  Мәтрүшкә, бөтнек, бака яфрагы,үги ана яфрагы;

- **Син ни өчен бер үсемлекнең үги ана яфрагы дип аталганын беләсеңме? Кешеләргә аның нинди файдасы бар?**
- **Әйткән сүзләрне хәтерендә калдырырга тырыш;**

  Бөтнек

  Мәтрүшкә

  Әрем

  Алабута

Энҗе чәчәге

Умырзая

Тамчы

Яңгыр

Бәс

Кар

Ә хәзер түбәндәге сорауларга төгәл итеп җавап бирергә тырыш:

Барлыгы ничә сүз әйтелде?

Бу сүзләр арасында чәчәкләр исеме бармы? Аларны әйт

Бу сүзләр арасында үләннәр исеме бармы? Аларны әйт.

Бу сүзләрне ничә төркемгә берләштереп булыр иде? Һәр төркемне әйт.

- **Охшаш сыйфатлары, билгеләре булган үсемлекләрне әйт. Мәсәлән, нинди үсемлекләр турында "сусыл", "ашарга" яраклы дип өйтеп була: алма, карбыз, әфлисун, груша һ.б.**

  Яшел һәм кытыршы;

  Шома һәм каты;

  Баллы һәм файдалы;

  Һуш исле һәм матур;

  Чәнечкеле һәм файдалы;

- **Шигырьне тыңла:**

  Безнең капка төбендә
  Үсә бер матур агач.
  Матур гына түгел әле-
  Серле, тылсымлы агач.
  Бу агач бик хикмәтле:
  Яфраклары юк бер дә.
  Яфрак-чәчәк урынына
  Башмаклар үсә көн дә.
  Кызыл алмага охшаган
  Туплар да үсә анда.
  Менә шундый агачны
  Күргәнең бар соң кайда?..

  Шундый гаҗәеп агачны күз алдыңа китер. Рәсемен яса. Аңа исем куш. Ул кайда үсә, сөйлә. Нинди җимеш бирә? Аны ничек үстерергә?

**Кушымта №5**

## МӘКАЛЬЛӘР, ӘЙТЕМНӘР

* Табигатьне саклаган – үз яшәвен аклаган.

* Язның байлыгы – кояш, көзнең байлыгы – уңыш.

* Көзге көн ул бала кебек: әле көлә, әле елый.

* Күз өчен яз яхшы, авыз өчен көз яхшы.

* Кышкы кар – көзге икмәк.

* Яңгыр яуса – җиргә май.

* Бер карлыгач килеп, яз булмый, бер саескан килеп, кыш булмый.

* Малың мал булсын дисәң, азыгың мул булсын.

* Терлекне кул белән генә сөймә, азык белән дә сөй.

* Кошның да туган оясы бар.

## ТАБЫШМАКЛАР

**Табигать күренешләре**

* Берсе яшел కеләм тукый,
Берсе сарыга мана.
Берсе ак мамыгын түши,
Ә берсе җыеп ала.

(Ел фасыллары)

* Тәңкә карлар сипкән,
Җирне ап-ак иткән,
Чыршы, каен, имән
Кардан чикмән кигән.
Бу кайчак? (Кыш)

* Ул булса, көн була;
Кл булмаса, төн була.

(Кояш)

* Ишегалдында таш була,
Өйгә керсә, су була.

(Боз)

* Йөзәм, ләкин суда түгел,
Йөзәм сезнең өстә мин.
Шат чагында ап-ак булам,
Кайчак кара төстә мин.

* Һәркөн диярлек
Елап яшь коя.
Килгән кошларны
Көнҗякка куа. Бу кайчак?

(Көз)

* Беркемгә дә күренмичә,
Җыр көйләргә ярата.
Көзге сары яфракларны
Тирә-якка тарата.

(Җил)

* Төнлә баксаң – күк тулган,
Итрә баксаң – юк булган.

(Йолдызлар)

* Колак, борынны уып,
Өеңә кертә куып.

(Салкын)

* Җәйге эссе көннәрдә
Мине сагынып көтәләр.
Мин аз гына күренсәм,
Качып-посып бетәләр.

(Болыт)

(Яңгыр)

**Үсемлекләр дөньясы**

* Җәй киенә,
Кышын чишенә.
(Агач)

* Төрле-төрле төстә алар,
Бу төсләр каян килгән?
Хушбуй исе аңкыталар,
Кем аны сөртеп йөргән?
(Чәчәкләр)

*Нечкә яшел сабакта
Юл буенда шар үскән.
Кай арада җил искән,
Ак шар очкан да киткән.
(Тузганак)

* Ап-ак күлмәген кигән,
Күлмәгенә тап тигән.
- Җәй башында җиләгемне
Авыз итәрсез дигән.
(Каен)

* Җәен киенә, кышын чишенә.
(Агач)

* Ап-ак күлмәген кигән,
Күлмәгенә тап тигән.
(Каен)

* Кигән ап-ак эшләпә
Төшереп кашына ук,
Эшләпәсен салдырсаң,
Каш түгел, башы да юк.
(Гөмбә)

* Алсу битле кыз үсте,
Кызарып җиргә төште.
(Алма)

* Озн, яшел – түтәлдә,
Сары, тозлы – кисмәктә.

* Язын дөнҗяга килә,
Көзен саргаеп үлә.
(Яфрак)

* Кигән ап-ак эшләпә,
Төшереп кашына ук.
Эшләпәсен салдыврсаң,
Каш түгел, башы да юк.
(Гөмбә)

* Ялгыш кына тисәгез дә,
Елатабыз, чагабыз.
Безгә үпкәли күрмәгез,
Шул – саклану чарабыз.
(Кычыткан)

* Сары эшләпә кигәннәр,
Җем-җем итәкүзләре,
Гел кояшка караганга
Кояш төсле йөзләре.
(Көнбагыш)

* Кышын да, җәен дә бертөсле.
(Чыршы, нарат)

* Нинди агач җилсез шаулый?
(Усак)

* Төрле-төрле төстә алар,
Бу төсләр каян килгән?
Хушбуй исе аңкыталар,
Кем аны сөртеп йөргән?
(Чәчәкләр)

* Кызыл төймә таптым,
Авызыма каптым.
(Җиләкләр)

* Җир астында җиз бүкән,
Һәркөн ашыйсың, иркәм.

(Кыяр)

* Үсеп утыра бер чүлмәк,
Өстенә кигән йөз күлмәк.

(Кәбестә)

(Бәрәңге)

*Туп түгел – түгәрәк,
Күсе түгел – койрыклы.

(Чөгендер)

**Табигать кочагында**

Гөл-чәчәкләр өзмәдек без.
Куаклар сындырмадык.
Яшел урман аланында
Уйнадык та җырладык.

Кояшка карап елмайдык.
Җилләргә сәлам әйттек.
Һәркем өйгә алып кайтты
Бер кочак сәламәтлек!

*Равил Фәйзуллин*

**Фасыллар**

Ел эчендә дүрт фасыл,
Дүртесе дә бик асыл.

Елгалар ярына кайтты.
Ташулар басылдылар.
Кояшка карап, елмаеп
Бөреләр ачылдылар.

Печән үсте, җиләк пеште,
Өзелеп җиргә төште.
Кош баласы җиләк кабып,
Үрелеп сулар эчте.

Сайрар кошлар очып китте,
Болытлар яшен түкте.
Таң алдыннан чәчәкләрне
Кыраулар төшеп үпте.

Урамнарга ак мамыктан
Юрган сыра бураннар.
Ай- һай җылы юрган, диеп
Сөенәләр урамнар.

*Галиәхмәт Шаһи*

**Булмагандыр буявы**

Көз килде дә тирә-юньне
Сары төскә буяды.
Яшелгә буяр иде дә -
Юктыр, ахры, буявы.

Тик сары төс агачларда
Бик озакка булмады.
Кыш килде дә бөтен җирне
Ап-ак төскә буяды.

*Вәкил Ахунҗанов*

**Яз**

Инде яз җитте,
Җирдә кар эреп бетте.
Салкын буранды көннәр
Кыш белән узып китте.

Иртән тәрәзәләрдән
Кояш яктысы төшкән.
Нинди матур сайрыйлар,
Кошлар да килеп җиткән.

Җылы һавада йөреп,
Агымсуларны күреп,
Күңелләрем хушлана
Язның рәхәтен белеп.

*Габделмәннан Рәхманколый*

**Нәрсә ул җил?**

- Кояшны, күкне, болытны
Күреп була, - ди Җәмил, -
Ә җилне бит күреп булмый,
Нәрсә соң ул, әни, җил?

- Соравың, улым, бик җитди,
Җил – күзгә күренмәс кул!
Ботка ашамаганнарны
Этеп кенә ега ул!

*Ринат Мәннә*

**Яңгыр ява**

Яңгыр ява! Яңгыр ява
Шыбыр-шыбыр.
Йөгереп чыга бала-чага,
Ыбыр-чыбыр.

Яшен яшьни, күкләр тетри
Дөбер-шатыр!
Курыкмыйлар, кулларында
Зонтик-чатыр...

*Илдар Юзеев*

**Кырау**

Кичә генә бакчабыз
Шау чәчәк иле иде.
Иртән уянып баксам,
Каралган барча гөле.

- Кырау суккан, - ди әни, -
Хараплар булган инде!
Ул тәртипсез кырауга
Яман ачуым килде.

Бакчаны ямьләп торган

Гөлләрем бик кызганыч.

Кырауның гүзәллекне

Аңламавы аяныч.

*Резеда Шәрипова*

**Томан**

_ Әтием, әйдә, бергәләп

Балыкка төшик инде?

- Улым, су буена күз сал,

Томан бераз таралсын.

Балык тотарга, әлбәттә,

Төшәрбез без аннан соң.

- Әти, эти, әйдә, киттек.

Мин бит эшне яратам.

Су буеннан ул томанны

Үзем куып таратам.

*Нәҗип Мадъяров*

**Чыршының күлмәкләре**

Яшҗ чыршылар киң итәкле

Күлмәкләрен кигәннәр.

Җитәкләшеп, бергәләшеп

Юл буена килгәннәр.

Энәле күлмәкләренә

Карап тордык сокланып.

Тик Равил берничә энә

Өзеп алды шукланып.

Апа әйтте: - Болай эшләү

Начар гадәт, бел менә:

Һәр чыршы күлмәк алыша

Җиде елга бер генә.

Без энәләрен йолкысак,

Чыршы күлмәксез калыр,

Җиде ел буена ничек

Күлмәксез яши алыр?

*Мәрзия Фәйзуллина*

**Урманда**

Кояш көлеп торганда

Килеп кердек урманга.

Урман безне кумады,

Без бит аның кунагы.

Җиләк белән сыйлады,

Шатлык эчкә сыймады.

*Заһирә Гомәрова*

**Миләш**

Кызыл болыт кунганмыни
безнең бакча түренә!
Минем яраткан миләшем
быел шулай күренә.

Теләсәң, как итеп кой!
Теләсәң, әчетеп кой!
Теләсәң, тәлгәше белән
киптерергә элеп куй!

Әй быел миләш, миләш!
Күзнең явын алырлык!

**Агачлар да авырый**

Яз башлануга Рәмиләнең әтисе көн дә бакчада була . Ул агач төпләрен йомшарта , корыган ботакларны кисә . Рәмилә әтисе янында йөрергә ярата .

- Әти , агач төбен нигә казыйсың ?
- Агач төбен йомшартам , кызым , - ди әтисе .
- Нигә йомшартасың аны ? - дип сорый Рәмилә .
- Йомшартмаган агачка су сипкәч, аның төбе катып кала. Су агач тамырларына кадәр үтә алмый . Тамырлар һава сулый алмыйлар .
- Агачлар да сулыймы ?
- Сулый , кызым . Алар өчен дә һава кирәк .

Беркөнне кемдер бакча ишеген ачык калдырган . Шуны гына көткән кәҗә бакчага кереп тә китә . Рәмиләнең әтисе , тиз генә чыбык алып , кәҗәне куып чыгара .

Рәмилә :

- Әти , нигә кәҗәне куасың ? – дип сорый .

Әтисе Рәмиләне бакчага алып керә , кәҗә кимерә башлаган агачны күрсәтә .

- Кимерсә ни була ?
- Агачларыбыз авырый , яфраклары саргая , үзе корып кала . Аннан соң ул алма бирми башлый .
- Агач та авырыймы?
- Авырый , кызым , хәтта корып ,үлеп тә китә .
- Бу алмагач та корыймы инде , әти ? – дип сорый ул , еламсырап .
- Бәлки , корымас , - ди әтисе . – Без бу агачны дарулап , бәйләп куярбыз .

Шуннан соң Рәмилә авыру агач янына көн дә килеп йөри башлый .Ул әлеге агачның бөтерелә, яшеллеген югалта башлаган яфраклары яңадан яшәрә башлавын күреп куана . Ә беркөнне ул, шатлыгыннан сикерә - сикерә, бакчадан әнисе янына йөгереп керә .

- Әнием , агач терелгән , яфраклары көлеп тора , - ди ул .

*Зәкәрия Әхмәров*